УЕН ЭШ ТҮГЕЛ

Газ шартлау белән бәйле фаҗигаләрнең сәбәбе – җавапсызлык

> 5

КОРОНАВИРУСНЫ ХӘМЕР

белән дәвалап буламы: уйдырма һәм чынбарлык

> 7

НАДИР БАҺАВИЕВ:

«Татар теленДә укысагыз, минем кебек акыллы булырсыз»

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 158 (28740) | Җомга | 29 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

Без укучыларыбызга янә шәп бүләк әзерләдек! 2022 елның беренче яртыеллыгына газетага язылучылар арасында мини-трактор уйнатачакбыз! Акциябезнең иганәчесе – «Уралец» сәүдә йорты белән әзерләнгән әлеге бүләк күңелегезгә хуш килер дип ышанабыз.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 20 гыйнварына кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

Бүләкне алу шартлары

1 2022 елның беренче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 «Ватаным Татарстан»ның «ВКонтакте» төркеменә язылырга һәм минитрактор уйнату турындагы хәбәргә репост ясарга. Яки «ВТ»ның «Инстаграм» сәхифәсенә язылырга, соңгы актуальдәге бәйге турындагы постны скриншот ясап, «ВТ»ның аккаунтын билгеләп, үзеңә урнаштырырга.

3 Язылу квитанциясен һәм «Инстаграм» яки «ВКонтакте» аккаунтыгызның сылтамасын безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне уйнатылачак.

Реклама 16+

Ишетми калмагыз

17,3 миллиард сумлык ярдәм

31 октябрьдә Пенсия фондының Татарстандагы бүлеге 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге мәктәп укучыларына, мәктәптә укуын дәвам итүче 18дән 23 яшькә кадәрге инвалидларга бер тапкыр 10 мең сум акча бирүгә гаризалар кабул итүне төгәлли. Шуңа күрә ведомство белгечләре «Путин акчасы»н әлегә алмаучыларга ашыгырга киңәш итә. Ведомство мәгълүматларына караганда, төбәктә 569,5 меңнән артыграк укучыга барлыгы 5,6 миллиард сумнан күбрәк күләмдә акча бирелгән. Моннан тыш Пенсия фонды 2 сентябрьдән 1 миллион 123 мең пенсионерга барлыгы 11 миллиард сумнан артыграк күләмдә акча күчергән. Ә инде ялгыз аналарга һәм йөкле хатыннарга ярдәм итү максатында җәмгысы 355 миллион сум юлланган.

Гомумән алганда, Пенсия фонды бүлеге җәйдән бирле «Путин түләүләре» буенча ялгыз аналарга һәм йөкле хатын-кызларга, балалар, пенсионерлар һәм мәктәп укучыларына барлыгы 17,3 миллиард сум акча җибәргән.

Исереккә көн бетә

Административ хокук бозулар турында яңа кодекс проектында, 16 яшькә кадәрге балаларны утыртып, исерек хәлдә автомобиль белән идарә иткән өчен җәза чарасын кырысландыру күздә тотыла. Бу хакта Россия Юстиция министрлыгы хәбәр итә, дип яза ТАСС. Шулай итеп, машинада сәрхуш хәлдә балаларны утыртып йөргән өчен 50 мең сум күләмендә административ штраф салу каралган. Моннан тыш исерек килеш рульгә утыручы 2–3 елга машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм ителергә мөмкин. Ә инде юл хәрәкәте кагыйдәләрен даими рәвештә тупас бозучылар (1 ел эчендә 3 һәм аннан күбрәк) 1–1,5 елга таныклыктан коры калачак.

Сүз уңаеннан, 2021 елның 9 аенда Татарстанда исерек килеш рульгә утырган 10676 йөртүче ачыкланган.

Ялларда җылы була

Ял көннәрендә Татарстанда кыска вакытлы яңгырлар явып узачак, көндез 11 градуска кадәр җылытачак. Бу хакта Татарстан Гидрометеоүзәге сайтында хәбәр ителә. Шимбә көнне төнлә һәм иртән юеш кар көтелә, көндез урыны белән аз гына яңгыр булырга мөмкин. Тәүлек дәвамында – көньяк-көнбатыштан секундына 15 метрга кадәр тизлектә җил. Төнлә 1–6 градуска кадәр суытып, иртән 0–5 градуска кадәр җылытачак. Көндез һава температурасы 4–9 градус җылы. Якшәмбе төнлә урыны белән кыска вакытлы яңгырлар көтелә, көндез аяз булачак. Төнлә – 2–7, көндез 6–11 градус җылы.

Киләсе атна башында республикада явым-төшемсез, җылы һава көтелә. Бу чорда тәүлеклек уртача температура нормадан 4–5 градуска югарырак булачак.

Районнарда ни хәлләр?

Балык Бистәсе

Олы Елга авылында 1879 елда төзелгән агач мәчет кабат ачыла. Бу –республиканың агачтан салынган иң борынгы мәчете, XIX гасырда татар агач архитектурасы үрнәге булган дини архитектура һәйкәле санала. Татарстан Мәдәни мирас объектларын саклау комитетында әйтүләренчә, реставрация вакытында бура күтәрелгән диварның 70 процентын саклап кала алганнар. Намаз бүлмәләре интерьерларын ясаганнар. Мәчетнең тышкы ягын һәм декоратив элементларын яңартканнар, тәһарәт алу өчен аерым бина төзелгән, шулай ук территория төзекләндерелгән. Янгынга каршы таләпләрне исәпкә алып, җылыткыч тышкы якка урнаштырылган.
(«Татар-информ»)

Азнакай

Хуҗасыз этләрне вакытлыча тоту пункты хәзер шәһәр читеннән яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча күптармаклы предприятие («МППБиО») базасына күчерелгән. Бүген әлеге оешма шәһәрдә сукбай этләрне аулау белән шөгыльләнә. Приютта 30 эт өчен урын каралган, аларны Андрей Усольцев карап, тәрбияләп тора. «Этне урамга чыгарып җибәрү – аннан котылуның иң җиңел ысулы. Сукбай көнендә калган ач этләр, чарасызлыктан, теләсә каян азык эзләп йөри. Мондый приют районда тәртип урнаштыру, кешеләрнең һәм дүрт аяклы дусларның иминлеген тәэмин итү өчен бик кирәк», – ди район башлыгы Марсель Шәйдуллин.
(«Азнакай»)

Баулы

Бөек Ватан сугышы ветераны Халик Кәримов 95 яшьлек зур юбилеен билгеләп үтте. Ул 1926 елның октябрендә Татар Кандызы авылында гаиләдә икенче бала булып туа. Аңа өч яшь тулгач, әтисе вафат була. Өч кечкенә бала белән әниләре тол кала. «Без кече яшьтән эшкә җигелдек. Нигездә, басуда эшләдек, чүп үлән утый идек», – дип искә ала балачак еллары турында ветеран. Ветеранга 15 яшь чагында сугыш башлана. Ул 1944 елның декабреннән 1945 елның маена кадәр сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Бүген Халик Кәримов сигез оныгы һәм 15 онықчыгына сөенеп яши.
(«Баулы»)

Тәтеш

Районда яшәүче 4 ятим бала фатирлы булды. Йортны Татарстан Президенты карамагындагы Дәүләт торак фонды төзегән. Һәр ятимгә 32 кв.м мәйданлы фатир тапшырдылар. Аларның берсендә гаиләсе белән Анастасия Туганова яшәячәк. Моңа кадәр алар кеше фатирында көн күргән. 2020 елга кадәр Дәүләт торак фонды ел саен 300 ятимне торак белән тәэмин иткән. Узган ел Татарстан Президенты карары белән бу сан ике мәртәбә арттырылды. «Быел 636 ятимне торак белән тәэмин итәчәкбез», – ди фондның башкаручы директоры Марат Зарипов.

КАЙГЫРТЫРГА ӨЙРӘНЕР ЧАК

30 октябрьдән коронавирус белән бәйле чикләү чаралары катгыйландырыла. Чикләү сәүдә үзәкләренә дә, төнге тормышка да, мәдәни чараларга да кагыла. Әлеге таләпләр эпидемиологик вазгыять тотрыкланганчы дәвам итәчәк.

НӘРСӘ ҮЗГӘРӘ?

• Коронавирус белән чирләмәгән яисә вакцина ясатмаган 60 яшьтән өлкәнрәкләр өчен мәҗбүри үзизоляция режимы кертелә;
• барлык җәмәгать урыннары һәм вакцина ясату кибетләре эшчәнлеге 23.00 сәгатьтән алып 6.00 сәгатькә кадәр туктатыла. Бу кагыйдә даруханә һәм ягулык салу станцияләренә кагылмый;
• теләсә нинди күңел ачу һәм массакүләм чаралар оештыру тыела;
• 18 яшьтән кечерәкләргә рәсми вәкил яисә ата-анасыннан башка сәүдә үзәкләренә йөрү тыела. Озата йөргән кешенең QR-коды булу мәҗбүри;
• мунча һәм сауналарның төнге сәгатьләрдә эшләве туктатыла.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЭШЧӘНЛЕГЕН ТУКТАТЫП ТОРАЧАК

• Бина эчендәге күңел ачу үзәкләре һәм аттракционнар;
• компьютер клублары;
• ломбард;
• боулинг-клублар;
• бина эчендәге сату күргәзмәләре, ярминкәләр.

КЕМНӘР ЭШЛИ?

Хакимият органнары, күпфункцияле үзәкләр, тормыш, көнкүрешне тәэмин итүче, өзлексез эшләүче предприятиеләр, белем бирү оешмалары үз эшен дәвам итәчәк. Оешма һәм шәхси эшмәкәрләр 30 октябрьдән алып 7 ноябрьгә кадәр оешма-предприятие эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәткәрләр санын үзләре билгеләргә тиеш. Республика буенча 170 вакцина ясату пункты бар, эшләми торган атнада алар хезмәт күрсәтүдән туктамаячак. 30 октябрьдән 7 ноябрьгә кадәр мобиль төркемнәр оештырачаклар. Алар эш урыннарына килеп, хезмәткәрләргә вакцина ясаячак.

QR-КОД КАЙДА КИРӘК?

• Аэропорт һәм вокзал эчендәге урыннардан кала барлык биналарда;
• мәйданы 150 квадрат метрдан арткан азык-төлек белән сату итми торган кибетләрдә, сәүдә үзәкләрендә һәм сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә;
• спорт, бассейн үзәкләрендә;
• аерым керү урыны булмаган кинотеатрларда;
• аквапаркта.

Моңа өстәп, 15 ноябрьдән башлап, QR-код түбәндәге җәмәгать урыннарына йөрү өчен дә кирәк булачак:
• теләсә кайсы кинотеатр;
• театр;
• концерт залы;
• физкультура комплексы;
• цирк.
QR-кодны күрсәткәндә, кайбер биналарда шәхесне раслаучы документ таләп итәргә мөмкиннәр.

Вазгыять нинди?

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Марина Патяшина белдергәнчә, республикада коронавируска бәйле хәл киеренке кала. Соңгы атнада чир йоктыру күрсәткече 27 процентка арткан. «Чикләүләр якындагы 1–2 атнага гына түгел, эпидемиологик вазгыять тотрыкланган чорга кадәр кертелде. Күңел ачу биналары, бәйрәм чаралары, кафе-рестораннарның төнге эшеннән вакытлыча баш тартып тора алабыз», – диде ул.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков сүзләренчә, коронавирус белән 17 меңләп медицина хезмәткәре көрәшә. Барлыгы 7,5 мең ятак әзерләнгән. Шуларның 9,5 проценты гына буш.

– Үлем белән идарә итәр өчен авыру белән идарә итәргә кирәк. Ә авыручылар белән бары тик ике юл белән генә идарә итәргә мөмкин. Беренчесе – чикләү чараларын кертү, ә икенчесе – вакцинация. Башка юл юк. Ил күләмендә авыручылар саны да, үлүчеләр дә арта. Вакцинаны вакытында ясатып өлгергән Германия, Бөекбритания кебек илләрдә үлүчеләр саны кимүгә таба бара, – диде министр.

Республиканың икътисад министры урынбасары Рөстәм Сибгатуллин бизнес вәкилләренә күрсәтеләчәк ярдәм чаралары хакында сөйләде. Кайбер ярдәм чаралары турында федераль хакимият вәкилләре дә әйткән иде инде. Алары турында карарлар шушы көннәрдә чыгачак.

– 2021 елда Татарстан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү өчен 1,2 млрд сум акча бүлеп бирде. Икътисад министрлыгына караган структураларның капиталлашуын исәпкә алып, бу ярдәмнең суммасы 3,55 млрд сумга җитте, – диде ул.

Татарстан буенча эчке эшләр министры урынбасары Алексей Соколов ялган QR-код һәм белешмәләр белән тотылган кешеләр өчен каралган җаваплылык турында искә төшерде.

– 30 октябрьдән башлап Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре ялган белешмә һәм QR-код ясау, сату, сатып алу һәм куллану очракларын ачыклау буенча тикшерүләр оештырачак. Вакцина ясату турында ялган белешмә кулланган өчен Россия Җинаять кодексының 327 маддәсе буенча җинаять җаваплылыгы каралган, максималь җәза – 6 айга кадәр кулга алу. Ялган кодлы кешене объектка керткән юридик зат 20.6 маддәсе буенча административ җаваплылыкка тартылачак. Ялган QR-кодтан файдаланган кеше генә түгел, аны ясаган затка да җавап бирәсе. Андыйларга 1 елга кадәр иректән мәхрүм итү җәзасы каралган. Җинаять ятьмәсенә медицина вәкиле җәлеп ителгән булса, аның бу адымы ришвәтчелек, ваемсызлык яисә вазыйфаи җинаять буларак бәяләнәчәк. Хокук бозган өчен 200 мең сум күләмендә штраф яки 2 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган, – диде ул.

Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева илдәге вазгыять аерым бер кешегә генә кагылмый, шуңа да хәзер бердәмлекнең ни икәнен күрсәтер чак дигән фикердә.

– Чиргә каршы тору өчен барыбызга да бердәм булырга кирәк. QR-кодлы таләпләр беркайчан да рәхәт һәм уңай булмаячак. Бу – безнең «комфорт зонасы»ннан чыгуыбыз. Әмма чыгарга кирәк, – диде ул. – Хәзер бер-беребезне кайгыртыр чак. Табигать безне үзе үк кайгыртырга өйрәтә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

«Татнефть» Директорлар советының Президент Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узган утырышында компаниянең быелның 9 аенда бюджет үтәлеше һәм ноябрьгә планнар турында сөйләштеләр. Утырышта экологик иминлекне арттыру хакында да фикер алыштылар. Шулай ук «Татнефть» төркеменең 2022 елга финанс-хуҗалык эшчәнлеге фаразы каралды.

Быел Татарстанда 25,6 млн тонна нефть чыгарылган, бу – узган елгыдан 1,1 млн тоннага күбрәк. Шуның 5 млн 237 тоннасы кече компанияләр өлешенә туры килә. Ел ахырына кадәр әлеге күрсәткеч 7 млн тоннага җитәр дип көтелә.

Татарстандагы нефть, газ һәм химия комплексының төп предприятиеләре быелның гыйнвар – сентябрь айларында җитештерү күләмен 3 процентка арттырган. Бу хакта «Татнефтехиминвест-холдинг» компаниясенең Директорлар советы утырышында оешманың генераль директоры Рафинат Яруллин сөйләде. 9 айда предприятиеләрдән озатылган продукция күләме 64 процентка артып, бәясе моңарчы күрелмәгән күрсәткечкә – 1 трлн 450 млрд сумга җиткән. Каучук бәясе соңгы 4 елда иң кыйммәтлесе булган. Икенче кварталда Европада полиэтилен, полипропилен, полистирол бәяләре рекорд куйган. Азот ашламалары соңгы 10 елда иң кыйммәтлесе булган. Нефть һәм нефть продуктларына дөньядагы бәяләр ковидка кадәрге чорда булганны узып киткән.

Шулай итеп, комплексның төп компанияләре төрле дәрәҗәдәге бюджетларга 499 млрд сум акча күчергән. Монысы исә узган елгыдан ике мәртәбә диярлек күбрәк. Татарстанның тупланма бюджетына кергән акча узган елгыдан 61 процентка күбрәк. Химия һәм нефть химиясе компанияләреннән әлегә кадәр бу кадәр акча кергәне булмаган.

Президент Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узган утырышта бу тармакка караган инновацияле проектлар турында да фикер алышу булды. Республика җитәкчесе аларның һәрберсе турында үз фикерен белдерде.

ТӨРЛЕЛЕКТӘГЕ КӨЧ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гран-прига Ханты-Манси автоном округы – Юграның «Югория» дәүләт телерадиокомпаниясе ия булды. 2021 елда бәйгегә «Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган иң яхшы медиапроект» дигән махсус номинация кертелгән. Һәм нәкъ менә әлеге номинациядә «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе беренче урынны яулады!

Кабат җиңү! Татарстан башкаласында Россия күләмендә журналистлар өчен игълан ителгән «Многоликая Россия» бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. Бүләкләү тантанасында без дә булдык.

«Многоликая Россия» Бөтенроссия журналистлар бәйгесе Россия территориясендә һәм аннан читтә яшәүче халыкларның милли традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен популярлаштыру, төрле халыклар мәдәниятенә кызыксыну уяту һәм хөрмәт тәрбияләү максатыннан үткәрелә.

– Татарстанда милләтара тынычлык һәм татулыкка бик зур әһәмият бирелә. Нинди генә милләт вәкиле булсаң да – аз санлымы, ишлеме – республикада һәркемгә хөрмәт белән карыйлар. Бу безнең күпгасырлык традицияләребез белән бәйле. Татарстанда 170тән артык милләт вәкиле яши. Күптеллелек, күпмилләтлелек, халыкларның гореф-гадәтләре һәм традицияләренә тугрылыкны саклауда журналистика мөһим рольләрнең берсен уйный. Милләтара мөнәсәбәтләрне саклауда без сезнең белән берлектә зур эш башкарабыз, – дип катнашучыларга мөрәҗәгать итте Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Быел матбугат чаралары «Телесюжетлар циклы», «Радиотапшырулар циклы», «Телепроект (документаль фильм, телепрограммалар циклы)», «Басма матбугатта язмалар циклы», «Интернет матбугат чараларында язмалар циклы», «Балалар һәм үсмерләр өчен мәгърифәтчелек проектлары» номинацияләрендә көч сынашты.

– Әлеге бәйгене инде 13 нче тапкыр уздырабыз. Бәйгегә 22 төбәктән барлыгы 800гә якын гариза кабул иттек. Алар барысы да Россиядә яшәүче халыкларның төрлелеген һәм бердәмлеген күрсәтә. Ә иң мөһиме – әлеге бәйге катнашучыларга тәҗрибәләре белән уртаклашырга мөмкинлек бирә, – диде «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев.

Бәйге җиңүчеләрен Ислам хезмәттәшлеге оешмасы каршындагы Россия Федерациясенең махсус вәкиле Рамазан Абдуллатипов та сәламләде. «Татарстанда бер генә милләт вәкиле дә, мәдәнияткә тә игътибарсыз калмый. Кайсы гына чорны алсаң да, республика җитәкчелеге халыкларның күптөрлелеген һәм бердәмлеген саклый алды. Татарстанның уңышы да шуңа бәйле. Республикада әхлак һәм тәртип тә шунын аркасында саклана», – диде ул.

Җиңүчеләр исемлегендә Татарстан матбугат чараларыннан тыш Ямал Ненец автоном округы, Мордовия, Дагыстан, Оренбург, Төньяк Осетия-Алания, Краснодар, Тула, Мари Иле, Пензадан килгән журналистлар да бар. Ә бәйгенең төп бүләге – Гран-при исә Ханты-Манси автоном округына китте.

ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Айдар ШӘЙХИН

Эш көннәре булмаган көннәр

Җәмгыятьтә көн саен бара торган үзгәрешләр телне дә яшәртә, камилләшергә һәм яңалыклар ачарга мәҗбүр итә. Бу атналарда иң еш кабатлана торган гыйбарәләрнең берсе – *«эшләми торган көннәр»*. Русчасы *«нерабочие дни»* дип атала торган бу күренеш уникаль хәл инде ул. Ял да түгел, эш көне дә түгел, шул ук вакытта кемдер эшли, кемдер рәхәтләнеп ял итә, ә максаты – кешеләрне бер урында җыелудан саклау. Кыскасы, акыл белән генә аңлап бетерә торган түгел.

Матбугат чараларында бу сүзне татарча «эшләми торган көннәр» дип бирә башладылар. Бу уңышлы вариант микән?

Кагыйдә буларак, руса-татарча сүзлекләрдә *нерабочий* сүзе *ял көне* дип тәрҗемә ителә. Шул ук вакытта *выходной* сүзенең дә *ял көне* дип тәрҗемә ителүе һәркемгә билгеле. Әгәр дә Президент Указы, Хөкүмәт карарлары һәм башка актларның теленә игътибар итсәк, анда «эшләми торган көннәр» белән «ял көннәре»нең махсус рәвештә аерым каралуын күрербез. Бу хәзерге ситуациянең закон өчен гомумән яңа булуы белән бәйле. Хезмәт кодексында *нерабочие дни* төшенчәсе бөтенләй юк. Әгәр дә коронавируска каршы көрәш чарасы буларак кертелгән ялларны рәсми рәвештә ял дип атасалар, бу көннәрдә эшләгән кешеләргә хезмәт хакын арттырып түләргә яисә башка төрле өстәмә чаралар кертергә тиеш булырлар иде. Шул сәбәпле, рәсми лексикада Россиядә кертелгән өстәмә ял көннәре «ял» дип аталырга тиеш түгел. Рәсми яңалык җиткерә торган матбугат чаралары бу урында аеруча игътибарлы булып, халыкка юридик яктан дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат җиткерүдән сакланырга тиеш.

Хезмәт кодексында һәм башка норматив-хокукый актларда очрый торган *нерабочие праздничные дни* сүзтезмәсе исә Татарстанда кабул ителгән актларда *эш көне булмаган бәйрәм көннәре* дип тәрҗемә ителгән. Аналогиягә нигезләнеп, *эш көне булмаган көн* дип яза алыр идек. Әмма бу конструкция тагын да уңайсызрак яңгырый.

Әгәр дә инкыйлабка кадәр кулланылган гарәп-фарсы алынмаларын кайтару дөрес дип уйласак, *тәгътил* дигән сүзне кертер идек тә, проблеманы хәл итәр идек. Тәгътил – каникул дигән сүз. Бу очракта аны шушы 1 атналык өстәмә ялларга карата кулланып та булыр иде. Әмма, ни кызганыч, бу кадәр иске һәм аз билгеле сүзләрне хәзерге сөйләмгә кертү уңышсыз булып санала.

Хакимият уйлап тапкан *нерабочие дни* сүзен тәрҗемә итеп җәфаланганчы, инглизчәдән кергән *локдаун* төшенчәсен генә кулланырга тәкъдим итүчеләр дә бар. Әмма бу да дөрес түгел, чөнки *локдаун* ябылу, карантин, изоляция очракларына туры килә. Ә безнең илдә кертелгән режим өйдә бикләнеп утырыны кайбер кешеләргә генә мәҗбүри итә. Бездә локдаун юк. Карантин исә беренче дулкын вакытында да кертелмәде. Мәскәү белән Санкт-Петербургта кертелгән режимны исә өлешчә локдаун дип атыйлар. Бу очракта инглиз терминын кулланырга була.

Әлхасыйл (кыскасы дигән сүз), ни атасы, ни анасы булмаган бу төшенчәне татарча ничек итеп дөрес атарга соң? Хәзерге вакытта матбугатта киң кулланылган *эшләми торган көннәр* варианты иң отышлы булып кала. Ул миңа ошамый, ул колакка ятышлы түгел, ул калька итеп тәрҗемә ителгән. Әмма рәсми стильгә яраклы.

Шәхсән үзем *эш көне булмаган көн* дип язу тарафдары. Тагын да уңайсызрак, билгеле. Әмма грамматика ягыннан карасак, *«Кем эшләми торган?»* дигән сыман сораулар калмый. Шуңа үземә мәгънәлерәк булып тоела. Өстәвенә Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән татарча закон текстлары кат-кат тикшерелгән һәм тәҗрибәле тәрҗемәчеләр кулыннан үткән. Аларга ышанасым килә.

Әгәр дә рәсми булмаган текстлар, гади аралашу һ.б. очраклар турында сүз йөртәбез икән, рәхәтләнеп *ял көннәре, Путин ялларь, өстәмә яллар, «кеше ял итә, мин эшли торган көннәр»* һ.б. җан теләгән вариантларны уйлап табарга һәм кулланырга була.

Әйтеп кенә бактым

Вәсвәсә

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Соңгы вакытларда иртәнге икеләрдә-өчләрдә уяна башладым. Бүген дә таң тишегеннән тордым. «Картлык килгәнен күрми калырмын дип куркып, төннәр буе йоклый алмый ятам», – дип яздым да баштa Разил Вәлиевкә, аннан «ВТ»ның «Ватсап»тагы төркеменә җибәрдем. Безнекеләр дәшмәде, ә минә Разил туганнан «Дөрес язгансың, картлык төнге караңгылыкта качып-посып килә ул» дигән хәбәр килде. Аның да минем шикелле «сандугач йокысы» гына йоклавын беләм.

Ярый әле кәрәзле телефон бар, анда «Ватсап» бар, ак кәгазьгә хат язсаң, кайчан барып җитә әле ул?! Ә болай рәхәт бит, хат язар өчен, төймәгә басып хат җибәрү өчен бер бармак җитә. Киләчәктә кешеләр бер бармаклы булып тумаслармы әле дигән уй да бар. Бит эволюция нәтиҗәсендә әнә күпме хайванның кыяфәте үзгәргән: койрыклары беткән, аяклары кыскарган, ияк киресенчә озынайган, йоннары коелган...

Кеше дә шул ук хайван инде ул, бары тик акыллырак кына. Интернет дигәннәрен дә бары тик кеше генә уйлап чыгара ала. Әмма интернет кайчак хайванлык та эшләп куярга мөмкин. Мәсәлән, бүгенге яшьләрнең кайберләре чынбарлыкны сизү-тою сәләтен югалтып, башка дөньяда яши башладылар кебек. Башка дөнья «теге дөнья» түгел, бүгенге, без яшәгән дөнья. Кайберәүләргә нигә ошамый икән ул, яшәү рәхәт, яшәү кызык бит! Әмма интернетка кереп тамыр җәйгәннәргә инде виртуаль чынбарлык кирәк. Инглиз теленнән кергән бу сүз «ясалма чынбарлык» дигән мәгънәне аңлата.

Ясалмалык болай да туйдырды инде, Фагыйлә апа әйтмешли, «чистый надаел». Телевизорны кабызсаң, экранга чыккан бөтен хатын-кыз чабата хәтле ясалма иренле. Сөйләгәндә иреннәре шапы-шопы итеп тора. Их, иреннәрегез трамвай ишегенә кысылгыры! Юк, кысылмасыннар, юкса ишек ябылмаячак.

«Ясалма» димәктән, дустым Алмаз Хәмзинның әтисе Наил абый сугышта бер аягын калдырып кайткан булган. Протез куйдырган бу. Протез дигәннәре ул елларны әйбәтләп шомартылган түгәрәк агач иде. Наил абыйга, әлбәттә инде, группа биргәннәр. Ә фәлән группа инвалид икәнеңне ел саен раслатырга, моның өчен комиссия узарга кирәк. «Комиссовать итү» дигән сүзләр әнә шул агач аяк заманнарыннан килә инде ул. Алмаз сөйләвенчә, комиссия узган саен табиблар Наил абыйның чалбар балагын күтәреп карый торган булганнар, янәсе, аяк үсмәгәнме. Монысы да – ясалмалык, тузга язмаган, уйлап чыгарылган кагыйдә, яңадан үсеп чыгарга аяк чәч түгел бит инде ул.

Төннәр буе вәсвәсәләнеп ятуым әллә чыннан да картлык микән? Әнә телефон тагын «келтин» итеп куйды. Уйларымны сизгән кебек, Разил туган миңа бер куплет шигырен җибәргән. Бу шигырь инде күптән көйгә салынып, яратып җырлана:

Әй син, картлык,
Кермә безнең өйгә.
Әй син, картлык,
Тимә Риманга!

«Әнигә» урынына «Риманга» дип куйган.

Кинәт кенә иҗат дәрте кузгалып китте дә Разилгә болай дип яздым:

Әй син, картлык,
Кил син иманга.

Ул тагын җавапсыз калмады, «үскәч, шагыйрь булырсың, ахрысы» дип язып җибәрде. Кая таба үсәсең бит инде, Разил туган, безгә аска таба үсәргә вакыт җитмәде микән? Шушы уйларымнан үзем үк куркып та калдым. Әнинең: «Картаю (карт аю) урманда гына була, улым», – дигән сүзләрен искә төшергәч, бераз тынычландым тагын.

Сәгать иртәнге дүрт тулып килә. Тизрәк эш көне башлансын иде дә, кеше арасына керергә иде. Дуслар белән кул җылысы тоеп исәнләшсә, аларның күңел җылысын сизеп тыңлыйсы килә. Уйлап чыгарылган дөньяның минем өчен бер кызыгы да юк. Бер уйлаганда, интернет күп мәгълүмат бирә, безне бер-беребезгә якынайта, берләштерә кебек, әмма мондый аралашу барыбер уйдырмага тартым. Интернетта һәркем аерым яши, ул – ялгыз һәм ялгызлыктан котылу өчен төрле кеше белән язышa башлый. Интернетта язылганнарның күпмесе дөреслеккә туры киләдер әле. Әмма кеше шуңа ышана, әле бөтен кешегә үзе күргән, үзе белгәндәй итеп сөйләп тә йөри. Кайберәүләрнең кызык өчен ялган язуы, сәясәткә йогынты ясау, ялган белән акча эшләве турында белми һәм беләсе дә килми. Үз-үзеңне алдау шул була инде ул.

Миңа исә җанлы аралашу җитми. Күзгә йокы элене башлады. Язганнарымны йокы аралаш саташу, «шайтан вәсвәсәсе» дип кабул итмәсләр микән инде? Итсәләр – итәрләр. Күңелгә килгәннәрне әйтә тору начар түгел дип беләм һәм иртәнге дүрттә язмама нокта куям.

ИСЕМЕНӘ КҮРӘ ҖИСЕМЕ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Дәүләт Советы депутаты

Россия Федерациясе Конституциясенә күптән түгел генә төзәтмәләр кертелгән иде. Алар турында хәзер фикер алышуның фәтүәте юк, алар инде хәзер – Төп Закон. Мәгълүм ки, Төп Закон өстәмә канун актлары белән ныгытыла. Һәм Дәүләт Думасы депутатларының шушы юнәлештә эшләве гаҗәп түгел. Алар яңа закон проектлары тәкъдим итәргә тиеш, аларның эшләре шул...

Озак көттермәделәр – 27 сентябрьдә Федерация Советының Конституция кануннары комитеты башлыгы Андрей Клишас һәм Дәүләт Думасы депутаты Павел Крашенинников «Россия Федерациясе субъектларында ачык хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» дип аталган закон проектын тәкъдим иттеләр. Әлбәттә, ПДФ форматы белән 174 бит тәшкил иткән, 65 маддәдән гыйбарәт бу документны әлеге ике кеше генә эшләмәгән, моңа күпләрнең хезмәте салынган. Һәм аны тиз арада беренче укылышта кабул итәргә җыенулары да төрле фикерләр уята. Шунысын да онытмаска кирәк: әлеге закон дәүләтебезнең федератив төзелешен күпмедер җайга салып торучы федерация субъектларындагы закон чыгаручы һәм башкарма хакимиятнең гомум принциплары турындагы №184 Федераль Законны тулысынча алыштырачак. Павел Крашенинниковның язуына караганда, әлеге закон проектына карата җәмәгатьчелектән килгән тәкъдимнәрне октябрь ахырына кадәр искә алачаклар, ә беренче укылыш инде 9 ноябрьдә була. Шикләнмәскә мөмкин, аны кабул итәчәкләр дә. Әмма бит әлеге закон проектын өйрәнеп чыгу өчен дә күп вакыт кирәк, һәм аның серләренә төшенү профессиональ юристларның гына хәленнән киләдер. Җәмәгатьчелек нишли ала? Ләкин шулай да дәүләтнең федератив нигезләренә яный торган кайбер үзгәрешләр бирелә бер карауга ук күзгә бәрелеп тора.

Дөресен әйткәндә, соңгы елларда илебезнең исеме болай да җисеменә туры килеп бетми башлады. Ә бу үзгәрешләрне кертүчеләр инде аның соңгы символларына кизәнә. Мин иң беренче нәүбәттә төбәк җитәкчеләренең фәкать «глава» дип аталырга тиешлеге турындагы үзгәрешне күздә тотам. Монда, әлбәттә, бары тик Татарстан турында сүз бара. Башка төбәк җитәкчеләре инде күптән «глава». Анысы аларның – үз эше. Ләкин без үзебезне һаман да Россия Федерациясендәге милли республика дип саныйбыз! Күптән түгел Татарстан Автономияле Республикасы төзелүгә 100 ел тулуны бәйрәм иттек. Татарстан Конституциясенең 89 маддәсендә Татарстан Республикасы җитәкчесе Президент дип аталa дигән сүзләр акка кара белән язылган. Ярар, федераль чиновниклар безнең Конституцияне санга сукмасын да ди. Сәяси культуралары шундый, димәк. Ләкин алар Россия Федерациясе Конституциясенең 77 маддәсен санга сугарга тиеш иде. Аның исә беренче өлешендә шулай ук акка кара белән «Система органов государственной власти республик <...> устанавливается субъектами Российской Федерации самостоятельно в соответствии с основами конституционного строя Российской Федерации...» дип язылган.

Бу мәсьәлә беренче тапкыр гына күтәрелми. Һәм аңа Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинның да мөнәсәбәтен яхшы беләбез.

tatarstan.ru

2015 елда бер пресс-конференциядә ул болай дигән иде: «Это действительно дело самого Татарстана, я не думаю, что это так чувствительно, что это заденет какие-то национальные чувства. Мы с уважением отнесемся к любому выбору народа Татарстана. Поэтому вы сами там решайте, ладно?»

Күптән түгел әлеге сүзләрне Президентның пресс-секретаре Песков та раслады: «В Кремле считают, что должность Президента в России должна быть одна. Но вместе с тем существует специфика некоторых регионов, в том числе упомянутого [Татарстана]. Президент с пониманием относится к такой специфике».

Без аның беренче җөмләсе белән дә килешәбез. Әлбәттә, Россия Президенты вазыйфасы берәү генә! Һәм ул вазыйфаны Владимир Владимирович Путин үти. Татарстан Президенты яисә Фәннәр академиясе президенты яки Татар ПЕН-Үзәге президенты вазыйфалары белән аны һич тә бутап булмый.

Әмма әлеге закон проектында дәүләтнең федератив принципларын инкарь иткән башка маддәләр дә бар. Мәсәлән, 4 маддәнең 3 булегенә игътибар итегез: «Федеральные органы власти могут участвовать в формировании органов исполнительной власти субъекта РФ, осуществляющих государственное управление в сферах образования, здравохранения, финансов, а также осуществляющих жилищный, строительный надзор, назначении на должность и освобождении от должностных лиц указанных органов исполнительной власти субъекта РФ в порядке и случаях, установленных федеральным законом».

Бу маддә закон булып гамәлгә керсә, милли республика җитәкчесенең нинди сүз белән аталуы бөтенләй әһәмиятсез булып кала! Төбәк башлыгының идарә срокларына чикләүләрне алып ташлау да бернинди роль уйнамаячак. Чөнки әлеге закон нигезендә төбәк башлыгын теләсә кайчан һәм бернинди сәбәпсез (хәер, эзләсәң, сәбәп тиз табыла ул) хакимияттән читләштерергә мөмкиннәр.

Татарстан Дәүләт Советы әлеге закон проектына мөнәсәбәтен соңгы сессиядә катгый белдерде: мондагы кайбер маддәләр Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килә! Документ Россия Дәүләт Думасында беренче укылышта кабул ителгәч, тикшерү, төзәтмәләр кертү өчен төбәк парламентларына җибәреләчәк. Әлбәттә, безнең депутатлар үз мәсләкләрендә калыр дип ышанам. Югыйсә паровоздан алда йөгеручe кайбер куштаннар хәтта милли республикаларны юкка чыгарырга дигән «үзгәреш»ләр дә кертергә мөмкин. Ә бу хакта хыялланучылар бар. Минемчә, әлеге закон проектын шул юнәлештә тагын бер адым дип бәяләргә була.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ГАЗ БЕЛӘН «СЕЗ» ДИП СӨЙЛӘШЕРГӘ КИРӘК

Соңгы арада газ шартлауга бәйле фаҗигаләр турында еш ишетергә туры килә. Яшел Үзәндә булган фаҗиганең кайтавазы тынарга да өлгермәде, Чаллыда газ шартлап, 5 кеше зыян күрде, 22 яшьлек кызның гомере өзелде. Россиянең башка төбәкләрендә мондый фаҗигаләр булып тора. Сәбәп нәрсәдә? Без ни өчен сабак алмыйбыз?

«ГазпромТрансгаз Казан» җәмгыятенең «Сабагаз» идарәсе җитәкчесе Ирек Мөхетдинов, газ куллануга җитди карарга кирәк, ди. Ул газ белән «Сез» дип сөйләшергә киңәш итә.

– Ничә еллар газ яксак та, әле дә аны ничек кулланырга кирәклеген белмәүчеләр бар, – ди ул. – Аны бары тик төп билгеләнеше буенча файдалану кирәк. Әйтик, газ плитәләрен бүлмәне җылыту өчен эшләтү катгый тыела. Ул сөрем газы белән агулану куркынычы тудыра. Аш бүлмәсе, ягу бүлмәләрендә газ приборлары эшләгән вакытта һава йөрсен өчен форточкалар ачык булу мәҗбүри. Өйләрен газ белән җылытучылар газны кушканчы ук төтен-җилләткеч юлларының төзеклеген карарга, аларның чиста, тыгылмаган булуын тәэмин итәргә тиеш. Әйтик, җәйләрен кошлар торба эченә оя корырга дип чүп ташып, суыру көчен киметергә яки юлларын томаларга мөмкиннәр. Төтен һәм вентиляция каналларындагы суыру көчен даими тикшереп торырга кирәк. Аларның түбәдән тышкы өлеше җитәрлек биеклектә булмаганда, җил үзгәргән очракларда суыру көче кими яисә бөтенләй кире якка эшләргә мөмкин.

Газ приборларын, мич горелкаларын үз белдегең белән алыштыру, төзек булмаган автоматикасыз файдалану, завод конструкциясен үзгәртү, газүткәргечләрне реконструкцияләү очракларына юл куелмаска тиеш. Бу таләпләрне үтәмәү шулай ук хәвеф-хәтәр китереп чыгарырга мөмкин.

– Салкын көннәрдә төтен һәм вентиляция каналларының башларын даими тикшереп тору аеруча мөһим. Чөнки тышкы һәм эчке температуралар аермасы аларның бозланып тыгылуына китерергә мөмкин, – ди Ирек Мөхетдинов. – Тагын шунысын да онытмыйк: көнкүреш газ җиһазларына ел саен техник хезмәт күрсәтелү кирәк.

Ә бит күп кенә йортларда тикшерүчеләрне кертмәүчеләр дә бар. Кемдер өенә чит кеше кергәнен өнәп бетерми, бераулар караклар дип курка. Әмма «ГазпромТрансгаз Казан» җәмгыятенең белгечләре һәрвакыт махсус киемнән йөри, аларның бу оешмада эшләгәнлеген раслаучы документлары бар.

20 елдан артык газчы булып эшләүче Идрис Кәримов, техник хезмәт күрсәтүчеләрне кертмичә, күп кенә газга кагылышлы эшләрне үзләре башкарган кешеләр соңыннан үкенә, ди.

– Газ – уен эш түгел. Үзе тоташтырган очракта да, беренче карашка бар да яхшы булырга мөмкин. Әмма шланг буш булып, әкрен генә газ чыгып та ята ала. Җыела-җыела шартларга да мөмкин, – ди ул. – Күп кенә йортларга кереп йөрим. Кешеләр вентиляция каналларын каплап куя. Һава йөрмәгәч, ничек газ йөрсен ди? Вентиляция эшен кәгазь куеп тикшереп була. Ул рәшәткәгә ябышса, димәк, йортта һава әйләнеше яхшы. Каплап куючылар, җил өрә бит, тараканнар керә, дип аклана. Гомерең турында уйларга кирәк. Андый кешеләргә яңадан инструктаж да үткәргәнебез бар. Әгәр җилләтү юлы төзек булса, сөрем газы чыккан очракта да зыян килмәячәк. Газ кулланучыларга тагын шунысын да әйтер идем: үз фатирларыгызда, йортларыгызда табигый газ, сөрем газын билгеләүче һәм сигнал ярдәмендә кисәтүче приборны урнаштырсагыз иде.

Әгәр техник хезмәт күрсәтү өчен өегезгә газчыны кертмисез икән, 2000 сум штраф түләттерергә мөмкиннәр. Башта техник хезмәт күрсәтү өчен кертмәгән дип фатирга әләгә алмау турында акт төзелә. Техник хезмәт күрсәтү өчен өйгә кертүне сорап почта аша хат килергә дә мөмкин. Әгәр шуннан соң да фатирга кереп булмый икән, бу хакта торак инспекциясенә хәбәр итәләр.

Сыйфат кирәк!

Шәһәрдә күп кенә йортларда шәхси җылыту казаннары урнаштырылган. Димәк, фатир шуның аша газ белән җылытыла. Бу очракта кайнар су да газ казаны аша килә. Аңа хезмәт күрсәтер өчен газ яки җылылык оешмалары белән килешү төзергә кирәк. Елга бер тапкыр хезмәт күрсәтү 3 мең сумнан башлана. Бу бары тик бер тапкыр килеп карап киткән өчен. Әгәр газ казаны ватылса, суны җылытмый башласа, аерым кеше чакыртып, моның өчен акча түләргә туры киләчәк. Хезмәт күрсәтү вакыты чыккан икән, аларны алыштыру кирәк. Бу эшләрне бары тик газ белгече генә башкарырга тиеш.

Ростехнадзорның Идел буе идарәсендә баш дәүләт инспекторы Зөфәр Нуриев газ шартлауларны киметү өчен техник хезмәт күрсәтүнең сыйфатын арттырырга кирәк дигән фикердә.

– Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе начар хезмәт күрсәтелүгә зарлана. Без аларга кая барырга кирәклеген аңлатып кайтарабыз. Иң элек кешеләр идарәче оешмага, әгәр соравы хәл ителмәсә, дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә тиеш. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә халыкка күрсәтелгән һәр техник хезмәт сыйфаты дәүләт торак инспекциясе тарафыннан тикшерелсен иде, – ди ул.

Казанның Имәнлек урамында яшәүче Нәсимә Сираҗиева газчыларны ике ел көтә икән инде.

– Әллә без өйдә юкта киләләр инде, беркем дә хәбәр бирми. Соңгы арада газга бәйле күңелсезлекләр күбәйгәч, акча түләп газчыга караттык. Үзебез белән бергә җиһазлар да картая. Газ казаннарын алыштыру, плитәләрне яңарту өчен акча кирәк, – ди Нәсимә Сираҗиева. – Кереп язу тутырып кына чыгып китүдән файда юк. Фатирларда газ системасын яхшылап карасыннар иде. Без – белгечләргә ышанабыз. Шуңа да ышанычны акласыннар иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ГАЗ ИСЕ КИЛСӘ, НИШЛӘРГӘ?

✓ Кичекмәстән газ җиһазларын сүндерегез;
✓ газ краннарын ябыгыз;
✓ тәрәзәләрне ачыгыз;
✓ электр җиһазларына кагылмагыз. Утны сүндерергә, яндырырга, телефонны зарядкага куярга ярамый. Шулай ук бу бинада тәмәке тарта күрмәгез;
✓ фатирдан яки йорттан бөтен кешене чыгарыгыз;
✓ кесә телефоныннан 04, 104 һәм 112 номерына шалтыратып, газ хезмәтен чакыртыгыз.

Сан

2021 елның сентябреннән хәзерге көнгә кадәр Россия төбәкләрендә **20**дән артык газ шартлау очрагы теркәлгән.

СӨРЕМ ГАЗЫ БЕЛӘН АГУЛАНГАНДА БЕРЕНЧЕ ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ

1. Сөрем газы белән агуланучыны кичекмәстән саф һавага алып чыгарга кирәк. Мөмкинлек булмаса, тәрәзәне, ишекне ачыгыз.
2. Кичекмәстән ашыгыч медицина ярдәме машинасын чакыртыгыз.
3. Кешенең кысып торучы киемнәрен салдырыгыз.
4. Башына һәм күкрәгенә салкын сулы компресс яки бозлы шешә куегыз. Чигәләрен аш серкәсе яки нашатырь спирты белән ышкыгыз.
5. Әгәр сулыш алмаса, ясалма сулыш һәм йөрәгенә массаж ясагыз.
6. Аңына килгәч, кайнар чәй эчертегез. 2–3 стакан чәй аның хәлен яхшыртачак.

ИСЕГЕЗДӘ ТОТЫГЫЗ!

• Газ җиһазлары начар, алардагы куркынычсызлык автоматикасы төзек булмаса;
• беркетеп куелган вентиляциядән газ чыгып торса;
• газ плитәсе өстендәге вытяжка торбасы вентиляция каналы тишемен тулысынча капласа;
• газ баганасы томалап куелса (белгечләр аны таба алмаса, газ чыгуны туктатып булмаячак);
• төтен юллыгының чистарту уемнары томаланган булса, газ шартларга һәм сөрем белән агуланырга мөмкин.
• Шулай ук газ плитәсе яки казан урнаштырылган бүлмәдә йокларга ярамый. Газ җиһазларын мөстәкыйль рәвештә урнаштыру тыела. Аны бары тик техник хезмәт күрсәтүгә килешү төзелгән махсуслашкан оешмалар гына башкарырга тиеш.

ЙОРТЫННАН ӘКИЯТ ДӨНЬЯСЫ ЯСАГАН ЧУЛПАН ГАЛИУЛЛИН:

«ҺӘРКАЙДАН МАТУРЛЫК ЭЗЛИМ»

Яшел Үзән районының Карагуҗа авылында үзенчәлекле, бик булдыклы кеше яши. Аучы, һөнәрче, балта һәм кул остасы, рәссам Чулпан Галиуллинның йорты, аның эчке бизәлеше гаҗәпкә калдыра һәм сокландыра. Хәер, могҗиза монда капканы ачып кергәнче үк башлана.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шүрәлеләр, аюлар…

Иң элек күзгә ташланганы: йорт каршында һәм ишегалдында үсеп утыручы агач, чыршылар. Шактый еллар элек Чулпан Галиуллин 10 төрле 24 агач утырткан булган. Монда талы да, слива, груша, каһәфер агачы да, миләше дә бар. Ишегалдында куе булып үсеп утыручы биек-биек чыршыларга да игътибар итмәү мөмкин түгел. Кайчандыр аларның да саны 24 булган. Бүген шуларның 18е ишегалдына ямь биреп утыра.

Шуннан соң күзебез йорт адресы язылган элмә тактага төште. Мәгълүматлар агачтан кисеп ясалган кондыз сынына язылган иде.

– Кондыз – безнең гаиләнең символы, – дип аңлатты моның мәгънәсен йорт хуҗасы. – Чөнки ул – иң тырыш җәнлек. Ул ясаган плотиналарның озынлыгы йөзәр метрга кадәр җитә. Кондыз бүлеп чыгарган сыекча – 150 авыруга дәва.

Капканы ачып кергәч, гаҗәпләнүебезне дәвам итәбез. Әйтерсең, ишегалдында әкият дөньясына эләгәбез. Биредә кунакларны агачтан ясалган төрле сыннар каршы ала. Убырлы карчык, аның «ире», башка төрле әкият геройлары, әллә ничә төрле таган, матур итеп эшләнгән сыерчык оялары, табигый таштан ясалган һәр төрле корылмалар… Биредә черегән тал агачы да эшкә җигелгән, аунап яткан башка материалга да «хуҗа» табылган.

– Аптырамагыз, мин бераз хыялыйрак кеше инде. Андый булмасам, боларның берсе дә барлыкка килмәс иде, – дип елмая хуҗа үзе.

Ишегалдына 9 тонна су сыйдырышлы, 1,30 метр тирәнлектәге җылытыла торган бассейн да ясап куйганнар. Җәй көне биредә һава температурасы 50 градуска кадәр күтәрелә ди. Шуннан соң хуҗа безне ял итү зонасына чакырды. Монда да һәркайсын – тандырын, коймак пешерә торган җайланмасын, пылау әзерләр өчен казан утыртып пешерә торган корылманы үз куллары белән ясаган. Шунда ук балык ыслау җайланмасы да тора. Бәйрәмнәрдә сатар өчен 160ар килограмм балык ыслыйлар икән.

Инде бар булган осталыгын ишегалдында күрсәтеп бетергәндер дип уйларга да өлгермәдек, хуҗа безне дүрт катлы йортына дәште. Анысын да үз проекты белән чит-ятлар ярдәменнән башка гына салып чыкканнар.

– Өйне 15 ел салдык. Ул елларда мондый зур йортлар яңалык иде. Бер чит кеше кулы тимәде бит шушыңа. Ике ел эчендә дүрт катлы йортны бары тик үз хезмәтебез белән генә салып чыктык, – дип сокландырды ул.

Йорт ишеген ачып керүгә кошлар сайравы, кул җылысы кергән гаҗәеп эшләр каршы алды безне. Моңа кадәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән сыннар дисеңме, урындык, өстәл, ишекләр, комод, телевизор астына куела торган җайланма, карават, картиналар, чәчәкләр булсынмы – барысы да шушы гаиләнең үз куллары белән эшләнгән эшләр. Өйдә хәтта агачтан ясалган крокодил сыны, каминга кадәр бар. Рәсем ясарга да оста булып чыкты яңа танышыбыз. Аларны да ул агачка төшерә һәм тулы бер сюжет линиясен булдыра. Уллары Ильяр да әтисе төсле иҗатка гашыйк икән. Шуңа күрә өйдәге рәсемнәрнең күпчелегенә аның кул җылысы тигән. Өйнең аскы катында спорт, ял итү бүлмәсе ясаганнар. Камины да, тренажерлары да, бильярды да, чәй эчә торган почмагы да бар биредә. Дүртенче катны исә «аучы йорты» итеп җиһазландырганнар.

«Һәр эшем – уникаль»

Аралашып, эшләгән эшләренә сокланып һәм гаҗәпләнеп йөргән арада Чулпан абыйның исеме белән дә кызыксынасы иттек. Чөнки мондый исемне ир-атлар арасында сирәк очратабыз. Ә аның тарихы чыннан да кызыклы булып чыкты.

– Без гаиләдә алты бала үстек. Мин – төпчегә. Әти яшь вакытта Чулпан исемле бер кызны яратып йөргән булган. Әни минем белән корсаклы вакытта әти: «Ул булса да, кыз булса да, исемен барыбер Чулпан куштырам», – дип әйткән дә үз сүзендә торган. Безнең авылда Чулпан исемле өч ир-ат бар иде. Хәзер икәү генә калдык, – дип сөйләде ул.

44 ел иңне-иңгә куеп яшәгән хатыны Фәридә ханым да иренә бик пар килгән. Ул да Чулпан абый кебек үк кул эшләренә бик оста. Бисердан чәчәкләр, гөлләр ясау, тегү-чигү белән шөгыльләнә. Чулпан абый агачтан нигезен ясаса, аларны гөлгә күмүче – Фәридә ханым. Кыскасы, ныклы нигез ирләр кулында булса, гаилә учагын саклаучы, өйгә ямь өстәүче – хатын-кыз.

Чулпан абыйның күпчелек эшләре тал агачыннан эшләнгән. Аның әйтүенчә, ул нык һәм җиңел. Шулай ук чимал итеп шомырт агачын да файдалана икән.

– Моңа кадәр хайваннар, җәнлекләр асрап, агач эшенә вакытым булмады. Соңгы 4–5 елда гына ешрак ясый башладым. Әле анысы да хобби буларак кына, башка хезмәт арасында гына эшләнгән эшләр, – ди оста.

Чыннан да, саный китсәк, булдырмаган, эшләп карамаган эше юк икән Чулпан абыйның. Ул 30 ел мәктәптә физкультура укыткан. Шул дәвердә урман кисүдә катнашкан, суган үстереп саткан чаклары да булган. Шуннан соң күп итеп мал асрап, сөт ризыклары сатканнар, балык ыслаганнар. Аннан соң җәнлекләр асраганнар.

– Аларны берничә ел тоттык. Гадәти, ак һәм кара төлке, чәшке, бурсык, саз кондызлары (нутрия) асрадык. Мин тиреләрен илим, хатын тегә. Кыйммәт йөри, ихтыяҗ да зур иде. Элек, алар бик популяр вакытларда, Казанның Шамил Усманов урамындагы базарга 40–50шәр чәшке бүрек алып барып сата идек. Бик популяр заманнары бар иде бит. Саз кондызының тиресеннән тун да тектердек хәтта. Шушы хезмәт белән җыелган акчага йорт салып чыктык, – дип искә ала Чулпан абый.

Бүген пенсиядә булса да, тик торганы юк аның. Әле дә булса бишәр үгез асрыйлар. Инде агачтан люстралар эшләү белән кызыксынып башлаган.

– Ясаган әйберләрне кеше күп сорый, ләкин берсен дә сату өчен эшләмибез. Акчаны да эшләп бетереп булмый. Агачтан эшләнгән һәр сын, һәр корылма – үзенчәлекле. Тормышыбыз түгәрәк, күңел тыныч. Тигезлектән аермасын. Мондый матурлык тусын өчен хыялланырга кирәк. Хыялсыз кеше – өметсез кеше, диләр. Тормышның матурлыгын, гүзәллеген күрә белү мөһим. Тормышны мин авыл хуҗалыгы белән чагыштырам. Монда да җирне вакытында эшкәртеп, чәчеп, ашлыгын җыеп алган кебек, һәр нәрсәне үз вакытында эшләргә кирәк. Уку, гаилә кору, балалар алып кайтуның да – үз вакыты. Барысы да тулы булганда гына күңел тыныч, эшкә ашкынып торасың. Ә күңел биреп башкарган эшнең нәтиҗәсе яхшы була, – ди Чулпан абый.

Бүген Чулпан абый белән Фәридә апаның өч оныгы бар. Аларны да эшкә өйрәтеп үстерергә тырышабыз, диләр.

– Балалар әти-әнидән үрнәк алып үсә. Аларны кечкенәдән эшкә өйрәтеп үстерү мөһим. Тырыш булганнарны гына бәхет көтә. Мин 15 ел урман кистем, бура бурадым. Улым 5 яшьтән үк шул эшләрне күреп, миңа булышып үсте. Баланы бары тик матур үрнәк нигезендә, хезмәт белән генә дөрес тәрбияләп була, – дип киңәшләрен җиткерде Чулпан абый.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЧУЛПАН ГАЛИУЛЛИННАН ТАНДЫР ЯСАУ СЕРЛӘРЕ

Тандырда ризыклар тәмлерәк, сусылрак килеп чыга. Кибетләрдәге тандыр, бердән, авыр булса, икенчедән, алар начар җылыта.

Тандыр ясар өчен иң элек төбенә кабыргасы белән кызыл кирпеч салабыз. Аннан соң табигый балчык сылыйбыз. Анысын үзебезнең сулык янында алабыз. Шуннан тимер челтәр (сетка), тагын балчык, шуннан соң өч кат фольга куябыз. Матур булсын өчен, тандырның тышын такта белән чорнап алдым. Эчендәге челтәргә бәрәңге, ит тезәбез. Итнең бөтен согы, мае бәрәңгегә агып төшә. Бик тәмле була. Шашлык 40–45 минутта пешә. Аны алгач, тандырга кабартма куябыз. Анысы 5–7 минутта өлгерә. Мин аны кешеләргә ясап сатмыйм. Ә менә киңәш сорап шалтыратучылар, килүчеләр булса, белгәннәрем белән рәхәтләнеп бүлешәм.

ХӘРӘМ ДӘВА

КОРОНАВИРУСТАН ХӘМЕР ГЕНӘ КОТКАРЫРМЫ?

Күптән түгел «ВТ» хәбәрчесе «Ватсап» социаль челтәрендә бер видеоязмага тап булды. Сезнең дә күргәнегез бардыр аны. Ник дигәндә, андый видеоязмалар тиз тарала, кулдан-кулга, дөресрәге, телефоннан-телефонга йөри. Иң яманы – шуңа ихластан ышанучылар бар. Бичара беркатлылык аяныч нәтиҗәләргә генә китермәгәе.

pixabay.com

Уйдырма һәм чынбарлык арасында

Видеоның асылы шунда: урта яшьләрдәге абый-апалар өстәл янында утыра. Араларыннан берсе, коронавирусны аракы эчеп җиңеп була икән, дигән фикерне әйтә. Бу хакта таныш бер дин әһеле сөйләгән икән, интернетта таралган, имеш. Хәмерне тотып куйганда кулланасы догасын да өйрәткән. «Фәни вә ти вә шифа» дип эчсәң, барлык чирләр юкка чыга, эчү гөнаһ булмый икән, ди.

Һич кенә дә аерым бер кешеләрне гаепләп, шәхескә кагылып, кешеләрнең яшәү рәвешенә дә тыкшынуыбыз түгел. Журналист буларак, фәлән-фәләннең фәләненнән ишетеп, белер-белмәс килеш әйтелгән сүзләренә кысылмыйча кала алмыйбыз, шул гына. Бит алар авызыннан чыккан җөмләләрдә, үрнәк итеп күрсәткән күренешләрдә кеше сәламәтлеге турында сүз бара!

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы да алкогольнең COVID-19 белән зарарлану куркынычын киметүдә берничек тә ярдәм итмәвен бер генә әйтмәде инде. Спирт, нинди генә рәвештә булса да, кешенең эчке органнары өчен зарарлы токсин булып санала. Канга кереп, ул организмда барган төп процессларны боза. Әйтик, метаболизм (матдәләр алмашыну. – **Ред.**) тизлегенә тәэсир итә, фермент һәм гормоннар барлыкка килүен тоткарлый. Баш мие күзәнәкләренә үтеп кереп, нейроннар үлеменә китерә. Монысы инде үзе артыннан башка аяныч нәтиҗәләрне алып килә. Кешенең ашкайнату системасы эшчәнлеге бозыла, шикәр диабеты барлыкка килү куркынычы арта, эшкә сәләте кими, игътибарсызлык, хәтер югалу кебек билгеләр пәйда була.

Спиртлы эчемлекләрне даими кулланганда кешенең иммун системасы эшчәнлеге дә кими. Ул саклагыч күзәнәкләрне үтерә һәм теләсә кайсы инфекция сагында торган ак тәнчекләр барлыкка китерүдән туктый. Хәмер белән дус булган кешенең гемоглобин, эритроцит дәрәҗәсе киму турында әйтеп тә торасы юк.

Замана зәхмәтеннән саклануның иң нәтиҗәле ысулы – гади гигиена кагыйдәләрен саклау, ди Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре. Хәер, бу тәгълиматны барыбыз да яттан белергә тиештер инде.

Белгечләр бу хакта нинди фикердә соң? Казан дәүләт медицина академиясенең педиатрия һәм неонатология кафедрасы доценты, башкаланың 1 нче балалар хастаханәсе педиатрия бүлеге мөдире Илдус Лотфуллин моны чираттагы миф, уйдырма дип атады.

> **Чирне алай җиңел генә җиңеп булса, пандемия дә болай озакка сузылмас, кешеләр дә чирләп, үлеп тормас иде.**

Мондый ышанулар нәрсәдән килә икән? Иң элек, дөрес мәгълүмат белән таныш булмаудан, укымаганлыктан, аңның караңгылыгыннан. Икенче яктан караганда, киеренке чор башланганда, кешеләрнең акыят, миф, ялгыш фикерләргә ышана башлавы да гадәти. Җиңел заман түгел бит хәзер. Бу шуңа да бәйледер, – дигән фикердә табиб. – Хәмер аерым кеше сәламәтлегe өчен генә түгел, җәмгыять өчен дә зыянлы. Исегездәдер, 1980 нче елларда шәһәрләрдә дә, авылларда да кешеләр исерткеч эчемлекләр белән ничек мавыкты! 1990 нчы еллар башында да дәвам итте бу. Хәмер эчүләр нинди фаҗигаләргә китерде, гаиләләр зыян күрде. Бу вакытлар кабатланмасын иде.

Юк-барга ышану кешеләрнең үзенә таяныч эзләвенә дә бәйле дигән фикердә белгеч. Шул ук вакытта болгавык заманнардан үзләре өчен файда алып калучылар да җитәрлек. Ерак эзлисе түгел: «моны сыласаң, чир эләкми», «монысын эчеп кенә коронавирустан терелдем» дип могҗизага тиң нәрсәләр тәкъдим итеп торучылар әллә нихәтле бит. «Кызганыч, фәнни, медицина ягыннан исбатланмаган кыйбатлы бәлзәмнәр, дару, биологик актив кушылмалар (БАД. – **Ред.**) сатып, кешенең соңгы акчасын каерып алырга әзер торган кешеләр бар. Аларга без үзебез дә тискәре карашны белдерергә тиештер», – ди табиб.

Шул ук вакытта халык медицинасы дигән төшенчә дә бар бит әле. Илдус Лотфуллин сүзләренчә, бу өлкәдәге күп еллар тупланган тәҗрибәне акыллы куллану практикасы бар. «Әмма шунысын истә тотарга кирәк: халык медицинасы борынгы заманнарда, дәвалау, тикшерену ысуллары булмаган чорда пәйда булган. Әйбәт тормыштан түгел, киресенчә, нәрсә белән дә булса дәваланыйк дигән фикердән бар булган медицина ул. Әлбәттә, ул заманча медицинаны алмаштыра алмый», – ди табиб.

Денсезлек

Җырчы-башкаручы, мөселман бәйрәмнәре алып баручы Ильяс Халиков сүзләренчә, халык дин әһелләреннән, дин, дини күренешләрдән көләргә ярата.

– Дуңгызны җиде кат мәчет тирәли әйләндерсәң, ул да хәләл була, дигән шаяру әле дә халык арасында бар. Хәмер эчеп, чирдән дәваланабыз дигән сүзләр дә үзеннән һәм диннән көлүгә тиңләшмәгәе. Спиртны рюмкалап эчеп түгел, тәнгә сылап, укол ясаганда кулланырга була. Медицина ягыннан аны файдалану ысуллары бик күп. Күрәләтә торып, динне мыскыллап, дога укып, хәрәм гамәл кылу кешенең диннән һәм үзеннән көлүен күрсәтә. Мондый күренешләр күңелне тырный инде. Гомумән, халык шундый булганга күрә Аллаһы Тәгалә шушындый чирләр белән сынамыймы икән әле?! – дигән фикердә Ильяс Халиков.

Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев бу мәсьәләгә бәйле сүзне бик кыска тотты.

> **Коронавирусны хәмер генә бетерсә, безнең илдә берәү дә чирләмәс иде. Безнең илдәге кебек аракы эчкән халык юктыр инде ул. Эчү – гөнаһ, аны шулай күрсәтеп, челтәрләрдә таратучысы да гөнаһлы, – дип, мондый мәгълүмат таратуны мәгънәсезлек дип бәяләде ул.**

«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин хәмер куллануның гөнаһ икәнен искәртеп, эчүгә кубрәк нинди кешеләр биреәүе турында аңлатты.

– Исерткеч эчемлекләр куллану – зур гөнаһ. Әмма дөньяда аның хәрәм икәнен белә торып та, бу начар шөгыльдән баш тартмаучылар байтак, – диде ул. – Беренчедән, дин ягыннан сай кешеләр эчүгә сабыша. Мондыйлар хәмер куллануның гөнаһ икәнен белми, аны хәрәмгә тиңләми. Икенчедән, артык ышанучы кешеләр. Болары инде – «ялган» табибларны тыңлаучылар. Алар медицина вәкилләренең: «Хәмернең файдасы бар», – дигәннәренә генә колак сала. Балачактан ук динсез гаиләдә тәрбияләнгән, шундый хәрәмле яшәү рәвешен күреп үскән кеше хәмерне үзенә үрнәк итәчәк. Кайтыдан онытылыр өчен бердәнбер чара хәмер булса, шатлык килгәндә бәйрәм итү чарасы да хәмер булыр. «Бәкара» сүрәсендә: «Синнән хәмер һәм отыш уены хакында сорасалар, әйт: «Ул нәрсәләрдә зур гөнаһ бар һәм кешеләргә аз гына файдасы да бар, ләкин файдасына караганда гөнаһы һәм зарары зуррак», – дигән сүзләр бар. Коръәни Кәримдә: «Әй, мөэминнәр! Исертә торган эчемлекләрнең, отыш уеннарының һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт итү – Аллаһтан башка мәхлукларга табыну эшләре, шулай ук ырымлау-багучылык эшләре – хәрәмдер, шайтан эшләреннән булган пычрак эшләрдер. Һәлак булудан котылу өчен бу нәҗес эшләрдән ерак булыгыз! Саклансагыз, шаять, котылырсыз – өстенлек табарсыз», – диелгән.

Педиатр-инфекционист Илсөя Заһирова да мондый дәвалану ысулын тәкъдим итүчеләрне аңламый.

– Мин, әлбәттә, хәмер куллануга каршы. Мантыйк ягыннан караганда, әйе, алкоголь канны сыекландыра. Тик бит аннан соң кабат куера башлый ул. Бу организмга сыеклык җитмәүдән башлана. Мондый профилактик ысуллар тәкъдим итү – сафсата. Аны куллана башласаң, эчкечегә әйләнергә мөмкин! – ди табибә.

УЙДЫРМА	ЧЫНБАРЛЫК
Алкоголь куллану вирусны юк итә.	Алкоголь куллану вирусны юкка чыгаруда ярдәм итми. Киресенчә, хәмер куллану сәламәтлек өчен куркыныч. Спирт (60 проценттан ким булмаган концентрациясендә) тән-тиредәге зарарлануларны дезинфекцияләү чарасы гына була ала.
Каты хәмер эчемлекләр эчү һавадагы вирусны юк итә.	Алкоголь куллану сулый торган һавадагы вирусны юк итми, авыз куышлыгын, тамакны дезинфекцияләү чарасы булып тормый.
Сыра, шәраб, спиртлы төнәтмәләр вируска каршы торырга булыша.	Алкоголь куллану иммун системасын зарарлый һәм кеше организмының вируска каршы торучанлыгын арттырмый.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

1 ноябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

05.00 «Җырлыйк әле!» 6+
05.50, 07.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре 12+
06.00 «Манзара» 6+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 22.40 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 00.00 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.30 «Точка опоры» 16+
17.00 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ» 12+
18.00 «Мин» 12+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» (Казань) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.50 «Семь дней +». Римзиль Валеев – журналист, общественный деятель 12+
01.15 «ТЫЕЛГАН МӘХӘББӘТ» 16+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 15.25, 17.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 21.55 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.30, 00.00 «Яңалыклар» 12+
09.25 «Әдәби хәзинә». Ленар Шәех (субтитрлы) 12+
10.00, 23.10 «КАЙДА СИН?» Беренче серия 12+
11.00, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
11.30 «Тамчы-шоу» 6+
12.25, 22.25 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.25 «Семь дней» 12+
14.30, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Точка опоры» 16+
18.20 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Ак барс» (Казан) – «Авангард» (Омск). Трансляция – Казаннан 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм» 6+
04.10 «Башваткыч» 12+
05.00 «Театрның кыллы колы» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 02.00, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «АЛИБИ» (S) 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 «МАТА ХАРИ» (S) 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут» 12+
14.55, 02.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «МЕДИУМ» 12+
23.40 «Вечер» 12+
04.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 11.55, 15.30, 17.40 Новости
06.05, 21.15 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 13.00, 03.35 Спец. репортаж 12+
09.30 «Игры Титанов» 12+
11.25 Бокс. Чемпионат мира. Трансляция из Сербии 0+
12.00 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Лос-Анджелес Темптейшен» – «Сиэтл Мист» 16+
14.20, 15.35 «АНДЕРДОГ» 16+
16.50 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
17.45 «Громко» Прямой эфир-
18.55 Хоккей. КХЛ. «Ак барс» (Казань) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция.
22.45 Тотальный футбол 12+
23.15 «МОЛОТ» 16+
01.35 Мысли как Брюс Ли. «БУДЬ ВОДОЙ». Док. фильм 12+
03.55 Новости 0+
04.00 «Человек из футбола» 12+
04.30 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «ПАРМА-ПАРИМАТЧ» (Пермский край) – УНИКС (Казань) 0+

НТВ

04.45 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 6.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.20, 10.20 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.20 «ЗА ГРАНЬЮ» (S) 16+
17.25 «ДНК» (S) 16+
18.30 «БЛИЗНЕЦ» (S) 12+
19.40 «БЛИЗНЕЦ» (S) 12+
21.20 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
23.55 «ИНСПЕКТОР КУПЕР. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
02.45 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.15 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «Реальная мистика». «Сатанёнок» 16+
07.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Сорока» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «РЕФЕРЕНТ» 16+
19.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР - 5». 1-я – 4-я серии 16+
23.10 «ПОДКИДЫШИ». 25-я и 26-я серии 16+
01.15 «Реальная мистика» 16+
02.15 «Порча» 16+
02.40 «Знахарка» 16+
03.05 «Понять. Простить» 16+
04.05 «Тест на отцовство» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ»–2 16+
07.00 «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня
09.20 «ССОРА В ЛУКАШАХ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25, 14.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ» 16+
14.00 Военные новости
18.30 «Специальный репортаж» 12+
18.50 «Легенды разведки». Док. сериал. Моррис и Леонтина Коэны 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №77» 12+
20.25 «Загадки века». Док. сериал. «Как передавали Крым Украине. Мифы и реальность» 12+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «СВЕТ В КОНЦЕ ТОННЕЛЯ» 12+
01.35 «КЛЮЧИ ОТ РАЯ» 12+
03.20 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ» 16+

2 ноябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

05.00 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
05.50, 07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
06.00 «Манзара» 6+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 22.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 23.30 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА» 16+
11.00 «Туган җир» 12+
11.30, 21.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Ком сәгате» 12+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Халкым минем...» 12+
16.30, 20.00 «Точка опоры» 16+
17.00 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.20 «Видеоспорт» 12+
00.45 «Семь дней +» 12+
01.10 «ТЫЕЛГАН МӘХӘББӘТ» 16+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 15.25, 17.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
09.25 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.00, 23.15 «КАЙДА СИН?» Икенче серия 12+
11.05, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.30 «Халкым минем» 12+
12.25, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.20 «И, туган тел...» 6+
13.35 «Театрның кыллы колы» 6+
14.30, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Точка опоры» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Новости Татарстана» 12+
21.50, 03.25 «Оныта алмыйм» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 02.00, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «АЛИБИ» (S) 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 «МАТА ХАРИ» (S) 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55, 02.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «МЕДИУМ» 12+
23.40 «Вечер» 12+
04.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 11.55, 15.30 Новости
06.05, 17.25, 19.45, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 13.00 Спец. репортаж 12+
09.25 «Игры Титанов» 12+
10.20 «Karate Combat 2021. Будущее» 16+
11.25 Все на регби!
12.00 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 Американский футбол. Лига легенд. Женщины. «Чикаго Блисс» – «Атланта Стим» 16+
14.20, 15.35 «ВОИН» 12+
17.40 Пляжный футбол. Межконтинентальный кубок. Россия – Япония. Прямая трансляция из ОАЭ
19.00 Футбол. Бетсити Кубок России. Жеребьёвка 1/8 финала. Прямая трансляция
20.30 Футбол. Лига чемпионов. «Мальмё» (Швеция) – «Челси» (Англия). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. «Ювентус» (Италия) – «Зенит» (Россия). Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов. «Аталанта» (Италия) – «Манчестер Юнайтед» (Англия) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Плавание. Чемпионат Европы (бассейн 25 м). Трансляция из Казани 0+

НТВ

04.50 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.20, 10.20 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.20 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.20 «ЗА ГРАНЬЮ» (S) 16+
17.25 «ДНК» (S) 16+
18.30, 19.40 «БЛИЗНЕЦ» (S) 12+
21.20 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
23.55 «ИНСПЕКТОР КУПЕР. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
02.45 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.15 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Реальная мистика». «Клуб бывших жён» 16+
07.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.35 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Шесть элементов» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР – 5» 16+
19.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР – 5». 5-я – 8-я серии 16+
23.10 «ПОДКИДЫШИ». 27-я и 28-я серии 16+
01.15 «Реальная мистика» 16+
02.15 «Порча» 16+
02.40 «Знахарка» 16+
03.05 «Понять. Простить» 16+
04.05 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня
09.20, 01.20 «СЕМЬ НЕВЕСТ ЕФРЕЙТОРА ЗБРУЕВА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25, 14.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. ЛИСЬЯ НОРА» 16+
14.00 Военные новости
18.30 «Специальный репортаж» 12+
18.50 «Легенды разведки». Док. сериал. Вильям Фишер 16+
19.40 «Легенды армии». Георгий Байдуков 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ДВА ДОЛГИХ ГУДКА В ТУМАНЕ» 12+
02.50 «КОЛОДЕЦ» 12+
03.15 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.35 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. ЛИСЬЯ НОРА» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 1–7 НОЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04) Акча мәсьәләсен уңышлы хәл итү өчен кәгазь «боткасы»на чумарга туры килер. Әмма хафаланасы юк: аны бик тиздән ерып чыгачаксыз. Аннан инде матди хәлегезнең бермә-бер яхшыруын гына көтәсе кала.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05) Тормышыгыз яхшы якка үзгәрәчәк. Ләкин моның өчен тырышырга, үзегезне тота белергә кирәк. Әйтик, өстенлегегезне күрсәтергә маташып, берәрсен ялгыш кына үпкәләтергә мөмкинсез. Шуңа күрә мондый әйберләрдән сак булыгыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06) Киләчәккә карыйсы килә башлар. Шуңа планнар кору байтак кына вакытыгызны алыр. Бәйрәм көннәрендә күңелле генә сюрприз көтегез. Бер танышыгыздан күңел кылларын тибрәндереп җибәрердәй яңалык ишетерсез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07) Өстәмә керем чыганагы барлыкка килү дөньягызны яктыртып җибәрер. Көтмәгәндә бик яхшы бер кеше белән танышу әйбәт кенә планнар коруга ярдәм итәр. Атна ахырында тормыш турында уйлану вакыт-вакыт үзегезгә тәнкыйть күзлегеннән карап алуның зыян итмәячәгенә төшендерер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08) Эштәге хәлләрнең җайлы гына баруына карамастан, уяурак булу, тирә-юньгә ешрак караштыру зыян итмәс. Хезмәттәшләрегез арасыннан берсе сезнең урынга утырырга тели сыман… Исәп-хисап ясаганда да игътибарлырак булыгыз: хаталану куркынычы юк түгел.

КЫЗ (24.08 – 22.09) Бу атна алдагысына караганда күпкә нәтиҗәлерәк булыр. Беренчедән, инде күптәннән күңелегезне тырнап торган бер мәсьәләгә ачыклык кертелер. Икенчедән, матди хәлегезнең яхшырып китүенә өметләндерердәй хәлләр килеп чыгар. Ә өченчедән…

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10) Ачуыгызны китергән хәлләр булып алыр. Аларга фәлсәфи күзлектән карарга тырышыгыз: шундук тынычланып калачаксыз. Атна ахырында бер туганыгыздан әйбәт кенә хәбәрләр ишетү үзегезгә көч-куәт өстәп җибәрәчәк.

ЧАЯН (24.10 – 22.11) Ачык йөзле, мөлаем, аралашучан булуыгыз катлаулы гына бер мәсьәләнең очына чыгарга ярдәм итәр. Бик җиңел генә! Бәйрәм көннәрендә туганнарыгыздан әйбәт хәбәрләр көтегез. Алар үзләренең тормышына үтеп керәм-керәм дип торучы яңалыклары белән сөендерер.

УКЧЫ (23.11 – 21.12) Бу атна сизелмичә дә узып китәр. Тигез җирдә проблема уйлап табучы дус-ишләрегезнең аптыратуын санамаганда, барысы да әйбәт булыр. Бәйрәм көннәрендә, «ковид еллары»нда күбрәк вакытыгызны саф һавада уздырырга тырышыгыз: үпкәләргә күбрәк кислород керсен (пандемия чорында табиблар да шулай киңәш итә бит).

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01) Вакытыгызны бары тик үзегезгә шатлык һәм чын мәгънәсендә канәгатьлек китерүче эшләргә генә багышлый алачаксыз. Атна уртасында күңел халәтегезне 100 процентка аңлардай бер кеше белән очрашып күрешү бәхетенә ирешәчәксез. Кыскасы, бик уңайлы, рәхәт чор!

СУКОЯР (21.01 – 19.02) Уңышлы атна. Шәхси тормышыгызда төшегезгә дә кермәгән шатлык-куанычлар көтелә. Керем артуны вәгъдә иткән хәлләр килеп чыгачак. Көтелмәгән чыгымнар да булачак анысы, әмма алар сезнең өчен авыр йөккә әйләнмәячәк.

БАЛЫК (20.02 – 20.03) Атна башында танышларыгыз әйбәт кенә яңалыклар белән куандырачак. Якыннарыгыз белән юктан да тавышланышып китә күрмәгез: юкса кайтавазы озакка барырга мөмкин. Фантазиягә бай булуыгыз эштә дә, өйдә дә зур файда китерәчәк.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, әти-әнисе

АРИФУЛЛИН
Рөстәм Иният улы,
АРИФУЛЛИНА
Фирүзә Зиннәтулла кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсе бухгалтерия учеты һәм хисап бүлеге баш белгече Арифуллина Лилия Рөстәм кызының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, әнисе

КУЗЬМИНА
Надежда Дмитриевна

вафат булу сәбәпле, танылган журналист, «Татарстан 24» ҖЧҖ директоры Кузьмин Андрей Владимировичның авыр кайгысын уртаклаша.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ҮЗЕҢӘ УКОЛ ЯСАУ НИГӘ КУРКЫНЫЧ?

Соңгы арада илдә табиб күрсәтмәсеннән башка гына коронавирустан үзләренә антибиотик кадаучылар арткан. Болай эшләү дөресме? Үз белдегең белән укол ярдәмендә чирне җиңәргә тырышу нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин?

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш терапевты, Республика клиник хастаханәсенең терапия клиникасы башлыгы Диана ГАБДЕЛГАНИЕВА шул сорауларга ачыклык кертте.

:: Диана Илдаровна, йорт шартларында үз-үзеңә укол ясау нәрсәсе белән куркыныч?

– Белер-белмәс үз-үзеңә укол ясау бик аянычлы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Уколны дөрес ясамыйча кеше утракса (седалищный) нервына зыян сала ала. Ул урында гематомалар пәйда булырга да мөмкин. Эш кораллары стерильләштерелмәгән булса, укол ясаган урын үлекле (сепсис) башлый. Шул рәвешле кан бозыла, кеше үләргә дә мөмкин.

:: Коронавирусны дәвалыйм дип үзенә-үзе антибиотик салучыларга ни диярсез?

– Болай эшләргә ярамый. Беренчедән, алар ковид вакытында, гомумән, булышмый. Антибиотиклар бактерияләргә каршы кулланыла. Ковид исә – вирус. Икенчедән, антибиотикларның тискәре йогынтысы да булырга мөмкин. Аларның кайбер төре йөрәк эшчәнлегенә зыян сала, икенче берләрен эчкәч, диарея башланырга, кеше гөмбәчек инфекциясеннән интегергә мөмкин. Шуңа күрә антибиотикларны белер-белмәс кулланырга ярамый. Аны укол итеп кадау турында сүз дә була алмый.

:: Кайбер кеше витаминнарны да шәфкать туташларына мөрәҗәгать итеп тормыйча гына үзенә-үзе сала бит...

– Витаминнарга гади генә әйбер итеп карау – зур хата. Аларны да табиб кушуы буенча гына кабул итәргә кирәк. Витаминнарны укол рәвешендә ясатырга кирәк булса, бу эшкә бигрәк тә җаваплы карарга кирәк.

:: Интернетта үз-үзеңә җайлы гына укол ясарга өйрәткән видеоларны да читләтеп үтәргә кирәк, димәк?

– Хәзер бөтен авыруны интернеттан укып дәваларга тырышалар бит. Эзли башласаң, анда шул ук ковидны, гипертонияне дә ничек дәваларга икәнен башыннан ахырына кадәр аңлатып бирәләр. Хәзерге заманда кешегә интернеттан нәрсәдер уку, ниндидер мәгълүмат туплауны тыеп булмый, билгеле. Ләкин сәламәтлек мәсьәләсендә анда язылганнарны читләп үтәргә кирәк. Әйткәнемчә, анда өйрәткәннәр буенча үз-үзеңә укол ясарга маташу бик аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

:: Кешегә, искәрмә буларак, өй шартларында үзенә-үзе укол ясарга рөхсәт ителгән очраклар бармы?

– Кеше өй шартларында үзенә бер төрле генә укол ясый ала. Ул да булса – инсулин кадау. Анда тиешле күләмдәге дару тутырылган шприц кулланыла. Ул кеше үзлегеннән дә ясый алырлык итеп эшләнгән. Башка барлык инъекцияләрне дә белгеч кенә ясарга тиеш.

Киңәш-табыш

ПАТЧИ ЯШӘРТӘ

Патчи – соңгы арада аеруча популяр булган күз тирәсенә куела торган туклыклы матдәләр сеңдерелгән пластинка. Күл астында алоэ гөле булган кеше аны үзлегеннән дә ясый ала. Алоэлы патчи пигментлы тапларны агарта, тирене тукландыра, дымландыра, ялкынсынуларны киметә. Аны ясау өчен алоэ яфрагын урталай кисеп, гель сыман согын мамыклы дискка сыларга. 20 минут суыткычта тоткач, күз, борын тирәсенә куярга була. Патчины 15–20 минут тотасы. Аны угычтан уылган кыярдан да ясарга мөмкин.

ГЕМОГЛОБИННЫ КҮТӘРӘ

Гемоглобинны күтәрү өчен түбәндәге төнәтмәнең шифасы зур. Аны ясау өчен 250 грамм башлы суганны ваклап турап, шуңа 200 грамм шикәр комы, ярты литр су салып, бергә болгаткач, сүрән утта 2 сәгать тотасы. Аннары шуңа 2 аш кашыгы бал салып болгатырга кирәк. Шуны 1 ай дәвамында көнгә 2 тапкыр ашаганнан соң 1 аш кашыгы күләмендә эчәргә кирәк.

СУГАННЫ ТАБАН АСТЫНА САЛ

Салкын тигән кешегә йоклаганда аякка оекбаш киеп, шуның эченә суган салып ятарга кирәк. Германия галимнәре шулай дип ышандыра. Баксаң, болай эшләгәндә кан да чистара икән. «Суганда фосфор кислотасы бар, ул организмга үтеп керә һәм канны чистартырга ярдәм итә, аннан патогеннарны һәм токсиннарны чыгара», – ди белгечләр. Моннан тыш суган табандагы кирәкле нокталарга йогынты ясап, дәвалый, билгеле бер органнарның эшчәнлеген яхшырта, кан әйләнеше бозылуга каршы тора икән. Суганны калын итеп кисеп, аны аяк табанына куегыз һәм өстеннән оекбаш киегез. Болай итеп төн буе йокларга да ярый. Суган исеннән курыкмагыз, бу процедурадан соң аяклар да, бүлмәдәге һава да яхшыра, дип ышандыра белгечләр.

Абау!

Көнчелек симертә!

Күптән түгел Италия галимнәре шундый ачыш ясаган. Neuropsychobiology журналында басылган фәнни-тикшеренү нәтиҗәләренә ышансаң, күпләр мәхәббәт билгесе дип санаган көнчелек – чынлыкта бик җитди чир. «Көнче кеше еш кына баш авыртудан интегә. Аның ашказаны, эчәк системасы да сафтан чыгарга мөмкин. Көнчелек корбаннары арасында йокысызлыктан интегүчеләр дә шактый. Көнчеләргә (бигрәк тә ир-атларга) симерү куркынычы да яный», – ди галимнәр.

Эремчек җыерчыктан коткара

А, В, С, Д витаминнарына, кальций, магний, фосфорга бай эремчек күзәнәкләр җимерелүне акрынайта, шул рәвешле бит тиресенә суларга ирек бирә. Моннан тыш ул бит тиресен дымландыра, тукландыра, җил, ультрашәмәх нурлар тәэсиреннән саклый. Җыерчыктан коткаручы эремчекле маска ясау өчен 2 чәй кашыгы эремчеккә 1 чәй кашыгы каймак өстәп, яхшылап болгатасы да 10 тамчы 2–3 процентлы водород перекисе тамызасы. Битне юып чистарткач, масканы биткә сөртеп, ярты сәгать тотарга кирәк. Соңрак аны җылы су белән юып төшерегез. Эремчек бит тиресен тукландыра, матур төс кертә.

ЙОДКА КЫТЛЫК КИЧЕРСӘҢ...

Күп кеше организмга йод җитмәүне авитаминоз белән бутый. Аның өчен икесенең дә билгеләре бер үк. Һәр ике очракта да кешене даими арыганлык, еш салкын тию, тырнакларның сынучанлыгы, чәч коелу кебек билгеләр борчый.

Йод дефициты сәламәтлек өчен бик куркыныч. Калкансыман бездә йод ярдәмендә эшләнә торган гормоннар кеше организмының барлык органнарына һәм системаларына йогынты ясый. Үсеп килүче организм өчен йод җитмәү аеруча куркыныч. Ул өч яшькә кадәрге сабыйларның психик үсешендә тоткарлыклар китереп чыгарырга мөмкин, ә олкәнрәк балалар үсештә артта кала, гәүдә авырлыгы арта һәм еш авырый. Йодка кытлык гормоннар синтезы бозылуга да китерә.

1 Организмның йодка кытлык кичерүеннән котылу өчен, иң беренче чиратта йодка бай ризыклар белән тукланырга кирәк. Атнага 2–3 тапкыр диңгез балыгыннан пешерелгән ризыклар кулланыгыз. Минтай балыгыннан әзерләнгән 80 граммлы 1 порция ризык организмда тәүлеклек йод нормасын тәэмин итә ала. Диңгез кәбестәсе шулай ук йод дефициты вакытында алыштыргысыз ризык булып санала. Тәүлегенә 200 грамм шундый су үсемлекләре куллану сезнең организмны кирәкле микроэлементлар белән баетачак.

2 Йодлаштырылган тоз белән «дуслашу» да зыян итмәс. Аның организмга кирәкле тәүлеклек күләме 5 граммны тәшкил итә. Бу – бер чәй кашыгы тоз дигән сүз. Әмма шуны исегездә тотыгыз: йодлаштырылган тозны әзер ризыкларга гына өстәргә кирәк. Чөнки пешергән вакытта йодның күп өлеше парга әйләнеп юкка чыга. Ә дозировканың артуы сәламәтлеккә зыяннан башка бернинди файда да китерми.

3 Йод кишердә, томат, баклажан, суганда, әфлисун, фейхоа, бакча җиләге, хөрмә, алма һәм әстерхан чикләвегендә бар. Аларга да өстенлек бирергә тырышыгыз.

4 Йод дефициты – мәкерле авыру. Күп кенә очракларда бу проблеманы махсус тикшеренү ярдәмендә генә ачыклап була. Көчле ару-талу, даими стресслар һәм дөрес тукланмау калкансыман бизнең эшчәнлеге бозылуга китерә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Белеп тор!

Каенанага ничек ярарга?

Кеше турында беренче күрүдә туган тәэсир иң көчлесе, диләр. Психотерапевт Дарья Милай таныш булмаган кеше турында уңай яки тискәре фикер туу өчен 2–4 минут вакыт җитә дип саный. Шуңа күрә киявгә чыгарга җыенучыларга булачак каенаналары белән очрашуга алдан әзерләнеп барырга киңәш ителә.

- ✱Булачак иргездән анның әнисенең кызыксынулары һәм нәрсә яратмавы турында сорашыгыз.
- ✱Егетегезнең әнисенә хөрмәт белән исеме һәм әтисенең исеме белән (Мәсәлән, Камилә Сәлимовна дип) эндәшегез.
- ✱Анның кызыксынуларын истә тотып бүләк әзерләгез.
- ✱Беренче очрашу сезнең файдага булсын өчен булачак каенанагыз белән ягымлы, нәзакәтле итеп сөйләшегез.
- ✱Тыныч, ихлас булыгыз, ясалмаланмагыз.

Көзге каникулны ничек уздырырга?

Зөһрә Садыйкова

Ниһаять, көзге каникул башлана. Коронавирус белән бәйле вазгыять аркасында быел әти-әниләргә дә балалар белән ял итү мөмкинлеге булачак. Ялларны авыру йоктырудан саклаып кына ничек күңелле һәм файдалы итеп уздырырга соң? Алда санап үтеләчәк барыбызга да таныш һәм гап-гади ысуллар ялларны истә калырлык итеп уздырырга ярдәм итәр.

БЕРГӘЛӘП ПЕШЕРҮ

Көзге салкын көннәрдә өйдә пешерелгән ризык белән тәмләп чәй эчүгә ни җитә! Балаларыгыз белән катлаулы булмаган печенье яки торт рецепты сайлагыз да бергәләп пешерегез. Ашаганда мактарга онытмагыз! Иренмәсәгез, бер атна эчендә балагыз ничә төрле «тәмлүшкә» пешерергә өйрәнергә мөмкин бит.

МОДА КҮРСӘТҮ

Балаларга шкафта тәртип урнаштырырга әйтеп торсагыз да, андагы пөхтәлек озакка сузылмаска мөмкин. Ә менә шкафны бушатып, андагы булган киемнәрдән мода күрсәтү оештырсагыз, балаларга бик ошаячак. Бердән, кайсы кием белән кайсы килешәчәген бала белеп торачак, икенчедән, артык киемнәрне алып куеп, кирәклеләрен генә калдыру сыгылып торган шкаф киштәләрен шактый бушатачак. Баланың мода күрсәтүдән алган илһамы шкаф җыештыруга да җитәчәк.

ФӘННИ-ПОПУЛЯР ВИДЕОЛАР АША ӨЙРӘНҮ

Ә сезнең балаларыгыз белән заманча фәнни-популяр видеолар караганыгыз бармы? Кыска, аңлаешлы роликлар аша балаларга кызыклы мәгълүматларны сеңдерергә мөмкин бит. Ни өчен зебра буйлы-буйлы, компасны ничек алдарга, ни өчен йокларга кирәк дигән гап-гади сорауларга җавап табу бала файдасына булачак.

КИНО КАРАУ

Коронавирус таралу сәбәпле, балалар белән кинотеатрларга барудан тыелып торсагыз яхшырак булыр. Нәкъ кинозалдагыча, попкорн алып, гаилә белән диванга тезелеп утырып, балалар өчен кызыклы булган фильм яки мультфильм карагыз. Балалар бик канәгать булачак.

КӨЗГЕ ФОТОСЕССИЯ ЯСАУ

Балалар белән көзге табигатьтә фотосессия ясау дигәндә, монда сүз аларны фотога төшерү турында гына бармый. Рольләрне алмашып, баладан фотограф ясау анның өчен тагын да күңеллерәк булачак. Әти-әнисен, җирдәге алтын яфракларны, янып торган кып-кызыл миләшләрне фотога төшереп, бала үзенә ләззәт алачак.

ӨСТӘЛ УЕННАРЫ УЙНАУ

Әллә кайчан онытылган, җыеп куелган домино, шашка, шахмат, хоккей һәм футбол кебек өстәл уеннары «чемпионаты» уздырырга мөмкин. Монда шулай ук бөтен гаиләгез белән катнашсагыз күңелле булачак.

АЛЬБОМ ТУТЫРУ

Соңгы вакытта фотоларны телефонда саклыйбыз. Күпләребез соңгы тапкыр фото ясап, альбом тутырганын хәтерләми дә торгандыр, мөгаен. Шунлыктан каникул көннәрендә телефондагы уңышлы фотолардан, көзге фотосессиядән фотоларны ясатып, һәр баланың шәхси альбомын бергәләп тутырып куйсагыз да яхшы булыр.

Кыскасы, әлеге киңәшләр каникул көннәрен төрләндереп җибәрер. Ялларны авырмый гына, балаларыгыз белән күңелле итеп уздырырга язсын!

Чүпрә чәчәк аттыра

Гөлләр шаулап чәчәк атсын, яфраклары сәламәт булсын өчен аларга өйдә ясалган гап-гади ашлама сибәргә киңәш ителә.

Кирәк булачак: 10 г чи чүпрә, 1 аш кашыгы шикәр комы, 1 л җылы су.

◆Чүпрәне суда эретергә һәм шикәр өстәп болгатырга. Ким дигәндә 2 сәгать торгарга кирәк.

◆Туклыклы катнашманы 1:5 исәбеннән су кушып болгатырга.

◆Үсентеләрне көзен һәм кышын айга бер тапкыр, ә язгы-җәйге чорда 10 көнгә бер тапкыр әлеге ашлама белән тукландырырга кирәк.

Чүпрәдә булган фитогормоннар, В төркеме витаминнары һәм ауксиннар күзәнәкләр бүленүне һәм үсемлекләрнең үсешен тизләтә.

Тәмле булсын!

Бәйрәм табынына кабымлык

Тәнзилә Идиятуллина рецепты

Кирәк: тарталетка, тавык ите, шампиньон, каймак, суган, тәменчә тоз, сыр.

Иң беренче эш итеп тавыкның түш итен вак итеп турап, тозлы суда тиз генә пешереп алырга һәм суын сөзәргә.

Туралган шампиньонны суган белән бераз тоз салып кыздырырга.

Кызгач, өстенә итне салырга. Бер кашык кибет каймагы өстәп болгатырга.

Суынгач, тарталеткаларга салып, өстенә сыр уарга һәм ул эрегәнче мичкә тыгып алырга.

«Кырмыска оясы»

Камыр өчен кирәк: бер кап атланмай яки «Пышка» маргарины, 2 аш кашыгы чамасы үсемлек мае, 4 аш кашыгы шикәр комы, бер чеметем тоз, ярты чәй кашыгы серкә белән сүндерелгән сода, он.

Болгату өчен масса: 2–3 аш кашыгы бал, 1/3 пачка атланмай, 2/3 банка куертылган сөт.

Йомшарган май яки маргаринга үсемлек мае, шикәр комы салып яхшылап болгатырга. Сүндерелгән сода өстәргә. Чама белән он салып, печенье камыры төсле итеп камыр басарга. Камырдан 4–5 сантиметр диаметрлы шарчыклар ясап, аларны он сибелгән кунага тезеп, 2 сәгатькә суыткычка куярга. Камыр бер тәүлек торса, ул тагын да тәмлерәк була.

Иттарткычтан чыгарылган камырны майлаган табага тезеп, алдан 180 градуска кадәр җылытылган мичкә куярга. 15–20 минуттан пешерергә.

Болгату өчен массаны кыска дулкынлы мичтә 3 минут эретергә. Кайнар массаны яхшылап тугларга һәм вакланган җылы камыр өстенә салып болгатырга. Аннары җылы килеш тәлинкәгә кырмыска оясы сыман өяргә.

КУРКА ТОРГАН УРЫН ТҮГЕЛ

Зиратны еш кына шомлы, куркыныч, җен-пәриләр яшәгән урын буларак тасвирлыйлар. Шулай да, барыбызны да сыендырачак мәңгелек йорттан курку урынлымы? Зиярәт кылуның үз тәртибе бармы?

Бу һәм башка сорауларга Наил хәзрәт ЙОСЫПОВ ачыклык кертте.

:: Хәзрәт, динебездә зират турында ни диелә?

– Ахирәт белән фани дөнья арасында бәрзәх дигән нәрсә бар. Ислам дине буенча, бәрзәхтә чакта тәнебез – кабердә, җаныбыз махсус бер урында була. Зираттагы кабер – ул безнең вакытлыча кала торган урын, бу һич тә мәңгелек йорт түгел. Шуны истә тотып, без зиратка барып җыештырабыз һәм мәрхүмнәргә дога кылабыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): «Зиратларга барыгыз, гыйбрәтләнегез. Ул – үлемне искә ала торган урын», – дип әйтеп калдырган.

:: Зират әдәпләре турында аңлатып үтсәгез иде.

– Зиратка барыр алдыннан тәһарәт алырга киңәш ителә. Кием чиста, пөхтә, хатын-кызларның тәне һәм чәче ябылган булырга тиеш. Зират юлында мәгънәсез сөйләшүләр һәм көндәлек мәшәкатьләрдән тыелып, зикер әйтеп барырга кирәк. Килеп җиткәч тә, капкага керү белән кабер әһелләрен сәламләп, шушы доганы укырга мөмкин: ***«Әссәләмү галәйкүм, йә әһлүл-кубүүр. Үә иннәә иншә Аллаһү бикүм ләәхикун. Нәс-әлуллаһә тәгәәлә ләнәә үә ләкүмүл гәәфийәһ».*** Гарәпчәсе истә булмаса, татар телендәге тәрҗемәсен әйтеп сәлам бирергә була: ***«Әссәламегаләйкем, йә каберләр әһелләре! Без дә кайчан да булса сезгә кушылачакбыз... Сезнең өчен дә, үзебез өчен дә Аллаһтан гафу ителүне сорыйбыз».***

Зират эчендә йөргәндә сак булу сорала, каберләрне таптамаска иде. Ике яисә берничә кеше бергә килгәндә, зиратта шаярмаска, көлмәскә һәм кычкырып сөйләшмәскә кирәк. Туганыгыз кабере янында шул кабер әһеленең гөнаһлары гафу ителүен, кылган изгелекләре, гыйбадәтләре кабул ителүен сорап дога кылу хәерледер.

Гомумән, зират әдәпләре мәсьәләсенә килгәндә, ислам динендә кабул ителгән кагыйдәләрне бозмау сорала. Әйтик, кабергә (чардуганга) ясалма чәчәкләр, уенчыклар, акча кую, фотосурәт төшерелгән кабер ташы урнаштыру – бу шәригатькә туры килми торган гамәлләрдер.

:: Зираттан куркырга кирәкме?

– Юк, исән кешегә зиратка керүдән куркырга кирәкмәс. Бары тик һәркемнән зират әдәпләрен үтәү сорала.

:: Хатын-кызларга, балаларга зиратка керергә ярыймы?

– Хатын-кызга мәрхүмне җирләгән вакытта гына зиратка керергә рөхсәт ителми. Әбү Хәнифә мәзхәбе буенча, хатын-кызга зиратка бару рөхсәт ителә. Электән бу мәсьәләгә карата ике төрле фикерләү бар. Ярамый дип әйтүчеләр моны сөекле пәйгамбәребезнең: «Каберләрне зиярәт кылган хатын-кызларга Аллаһның фәрештәләре ләгънәт укырлар», – дигән хәдисенә таянып әйтәләр. Әмма пәйгамбәребезнең икенче бер хәдисендә: «Мин элек тыйганны рөхсәт иттем», – диелә. Элек җаһилият (мәҗүсилек. – **Ред.**) заманында хатын-кызлар тиешенчә киенә, госел тәртипләрен үти белмәгән. Шул вакытта аларга зиратка бару тыелган булган. Соңыннан рөхсәт ителгән. Бер хатын-кыз зиратта елап утырганда, сөекле пәйгамбәребезнең аңа: «Ник елыйсың, кабер янында еларга ярамый!» – ди. Ул аңа: «Нишләп кабер янында утырасың?» – дими бит. Хәдисләрдән без Гайшә анабызның да энесе Габдулла өчен кабер янында дога кылуын беләбез. Шуңа да хатын-кызга, госелле булса, башына яулыгын бәйләсә, тиешенчә киенсә, күрем вакытына туры килмәсә, аңа да зиратка бару тыелмый.

Балаларга да зиратка керү тыелмаган. Ләкин монда берничә әйбергә игътибар итәргә кирәк. Беренчедән, баланы зиратка нинди максат белән алып керәсез? Икенчедән, кечкенә баланың психикасына зыян китерерлек гамәлләр кылынмасмы? Ә, гомумән алганда, балаларга ахирәт турында, һәрбер гамәлебез өчен җавап бирәсе булу турында белү мәслихәт.

:: Өлкәннәрдән: «Зиратка бармак белән төртмә, күрсәтмә!» – дигәнне ишеткән бар. Нәрсәгә бәйле ул?

– Гомумән алганда, бармак белән төртеп күрсәтү һәм бер-беребез белән аралашканда бармак белән ишарә итү – әдәпсезлек билгесе. Дингә килгәндә дә, зират әдәбе турында сөйләгәндә дә әлеге тәртипләр саклана.

:: Зиратта ятып, утырып торырга, зиратта үскән җиләк-җимешне ашарга, үләнен чабарга ярыймы?

– Зиратта ятып, утырып тору тыелмый. Тик кабер өстендә генә түгел! Җиләк-җимеш экологик чиста җирдә икән, исраф булмасын дип, ашарга яисә аны сатып, зиратка берәр кирәкле әйбер алырга мөмкин.

Үләнне чабарга ярый һәм кирәк тә. Тик чамасын белеп! Кабер ташларына, чардуганнарга зыян китермәү мөһим.

:: Кабер ташларын алмаштырып тору кирәкме? Йә бер тапкыр кую да җитәме?

– Кабер ташы мәрхүмнәребезнең күмелгән урынын табар өчен куела. Әгәр дә кабер ташы ватылса, искерсә яисә үлгән кешенең исеме күренми башласа, шул вакытта аны яңага алмаштырырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) Госман бин Мәзгунны күмгәндә таш куя һәм: «Шушы тамга буенча мин аның каберен танырмын һәм үземнең туганнарымны да аның янына күмәрмен», – дигән сүзләр әйтә.

:: Хәзрәт, зиратка әйбер алып килсәң, аны шунда ук калдырырга кирәк, диләр бит. Әйтик, өмәләр вакытында кемдер тырма, көрәк, буяулар алып килә. Димәк, алар шунда калырга тиешме?

– Юк, калдырырга кирәкми. Алып кайтырга ярамый дию – хорафатлык. Кулланылган әйберләрнең кирәкмәгәнен, чүп-чарны зиратның чүп савытына ташларга була. Ә инде көнкүреш өчен кирәкле көрәк, тырма, пычкы ишеләрне, әлбәттә, кире алып кайтырга кирәк.

dumrt.ru

Ноябрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ясту намазы
1	Дүш	04:43	06:49	14:10	16:03	17:48
2	Сиш	04:45	06:51	14:08	16:01	17:46
3	Чәрш	04:47	06:53	14:06	15:59	17:44
4	Пәнҗ	04:49	06:55	14:04	15:57	17:42
5	Җом	04:50	06:58	14:03	15:55	17:40
6	Шим	04:52	07:00	14:01	15:53	17:39
7	Якш	04:54	07:02	13:59	15:51	17:37
8	Дүш	04:56	07:04	13:57	15:49	17:36
9	Сиш	04:57	07:06	13:55	15:47	17:34
10	Чәрш	04:59	07:08	13:54	15:45	17:32
11	Пәнҗ	05:01	07:10	13:52	15:43	17:31
12	Җом	05:03	07:12	13:50	15:41	17:29
13	Шим	05:04	07:14	13:49	15:40	17:28
14	Якш	05:06	07:16	13:47	15:38	17:27
15	Дүш	05:08	07:18	13:46	15:36	17:25
16	Сиш	05:09	07:20	13:44	15:35	17:24
17	Чәрш	05:11	07:22	13:43	15:33	17:23
18	Пәнҗ	05:12	07:24	13:41	15:31	17:22
19	Җом	05:14	07:26	13:40	15:30	17:20
20	Шим	05:15	07:28	13:38	15:28	17:19
21	Якш	05:17	07:30	13:37	15:27	17:18
22	Дүш	05:19	07:32	13:36	15:26	17:17
23	Сиш	05:20	07:34	13:35	15:24	17:16
24	Чәрш	05:22	07:36	13:34	15:23	17:15
25	Пәнҗ	05:23	07:38	13:33	15:22	17:15
26	Җом	05:24	07:40	13:31	15:20	17:14
27	Шим	05:26	07:41	13:30	15:19	17:13
28	Якш	05:27	07:43	13:30	15:18	17:12
29	Дүш	05:29	07:45	13:29	15:17	17:12
30	Сиш	05:30	07:47	13:28	15:16	17:11

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Белеп тор!

МӨСЕЛМАННЫҢ ҖОМГАСЫ

Җомга без нинди гамәлләр кылырга тиеш? Бу көнне:
- балаларга бүләкләр алып, аларны куандыру;
- ярлыларга ярдәм итү;
- каберләрне зиярәт кылу;
- сәдакалар бирү;
- якыннарыңның, туганнарыңның, бигрәк тә әти-әниеңнең хәлләрен белешү, аларны куандыру;
- госел-тәһарәт алып, матур, пөхтә киемнәр киеп, мәчеткә бару, кардәшләр белән күрешү – хәерледер.

Расүлебез: *«Җомга көнендә бер вакыт бар, әгәр дә шул вакытта намаз укучы мөселман кешесе Аллаһыдан берәр хәерле нәрсә сораса, Раббыбыз аңа аны бирәчәк», – дип әйткән.*

Сәхифәне Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

РАУШАН МИННЕГАЛЕЕВ:

«БИЛГЕЛЕ БЕР КЫСАГА «СЫЕШУ» КЫЕН»

Бу юлы без «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка Азнакай егете, гел елмаеп йөрүче Раушан МИННЕГАЛЕЕВны чакырдык. Кысалар, блогерлык, иҗади тандем һәм хыяллары турында сөйләштек.

:: Синең турында бик аз беләбез. Балачагың турында сөйлә әле.

– 1997 елда Азнакайның үзәк хастаханәсендә искиткеч бер бала дөньяга аваз сала *(көлә)*. Шаяруларны читкә куеп торсак, кечкенә чакта мин бик актив булганмын. Сәбәпчеләре – әтием белән әнием. Алар мине төрле яклап үстерергә теләгән. Азнакайның нәкъ үзәгендә яшәгәч, төрледән-төрле түгәрәкләргә йөрергә уңайлы булды, шуңа да өйгә кайтып керми идем. Озак кына биюгә йөрдем. Татар биюен оста бии идем, кадерле кунаклар килгән саен мине чакыралар иде. Нинди генә бәйге булмасын, барысында да катнашырга тырыштым. Кыскасы, игътибар үзәгендә үстем, һәм бу миңа бик тә ошый иде. Алга таба кызлар белән танышуда да, көндәлеккә куеласы билгеләрне күтәрүдә дә ярдәм итте әле ул.

:: Казанга ничек килеп чыктың?

– Мәктәпне тәмамлагач, әти-әнием якынрак җирне сайларга үгетләсә дә, Казанга китәргә карар кылдым. Кала белән бик таныш булмасам да, үз урынымны нәкъ менә биредә табармын кебек тоела иде. Казанның сәнгатькә гашыйк студентлары белән дә дан тотучы энергетика университетына укырга кердем. Биредә дә, нәкъ мәктәптәгечә, бер чараны да калдырмадым диярлек. КВНда төп составка алдылар. Шактый чараларда катнаштык, юмор белән дуслык көннән-көн артты. Шул ук вакытта «Инстаграм»да үз блогымны башлап җибәрдем. Аны актив алып бармасам да, күңелдә блогер булу хыялы яши бирде. Ә университетта, минем юнәлеш түгел бу, дигән уйлар белән генә укып йөрдем. Менә шушы укудан тыш булган чаралары, биредәге якын кешеләрем генә «тотып торды».

«Эштән киткәндә, кесәмдә нибары биш мең сум акча бар иде...»

:: Блогер булганчы кайда эшләдең?

– Университетны тәмамлагач, сату буенча менеджер булып эшли башладым. Командировкаларда йөри-йөри, әти-әнием, якын дусларым белән аралашырга да җай калмагач, бер елдан соң киттем бу эшемнән. Инвестицияләр өлкәсендә эшли башладым. Сату өлкәсендә осталыгым булмаганны күреп, җитәкчебез SMM-белгеч булырга тәкъдим итте. Бер төзелеш оешмасының социаль челтәрләрен алып бара башладым. Ошаттылар. Яхшы телефон алып бирделәр. Эшләә генә! Һәм мин эшләдем дә. Шуннан соң бер музыкаль лейбл үз социаль челтәрләрен алып барырга тәкъдим итте. Бу эшкә баштанаяк чумдым. Ай ярым – ике ай тирәсе эшләгәннән соң, «сүнгән» кебек булдым. Моны җитәкчеләр дә сизеп алды бугай: «Талантың бар, ләкин без аны ача алмадык. Бар булган көчеңне шәхси сәхифәңә биреп кара әле», – диделәр. Үземә дә булдыра алырмын кебек тоелды.

Соңгы эшемнән киткән вакытта, кесәмдә нибары биш мең сум акча бар иде. Кешедән әҗәткә алып тордым да туган якка кайтып киттем. Өч көн буе алга таба нишләргә, акча каян алырга, фатир кирәк, шәхси тормыш турында да уйлый башларга иде дигән уйлар белән йөрдем. Борчылдым, шул ук вакытта туктап хәл алырга кирәклеген дә аңладым. Теләсән, җае да туры килеп тора бит аның! Минем белән элемтәгә бер продюсер чыкты. Мин – аңа, ул миңа ярдәм итәргә сүз куештык. Телефон алырга кушылды. Курка-курка гына «рассрочка»га телефон алдым. Шуннан клиентларым да барлыкка килә башлады. Мин аларга үз сәхифәләренә кызыклы контент ясарга ярдәм итәргә тиеш идем. Шул ук вакытта үз сәхифәм турында да уйладым. Вак-вак адымнар һәм зур тырышлык белән бүгенге нәтиҗәләргә ирешә алдым.

> Кешеләр миңа, энергетикаң яхшы, диләр. Килешәм. Үземә карап торганнарын да яратам. Миңа карагач елмаялар икән, бу ни турындадыр сөйли инде.

:: Раушан, хәзер бит яшьләрнең күбесе синең кебек уйлый, ләкин бөтен кеше блогер булып битә алмый.

– Килешәм. Яшьләр булган мөмкинлекләрне күрә, алардан файдалана белә, тиз өйрәнә, өйрәнгәннәрен шундук куллана. Бөтен ишекләр ачык була торып, кысан офиста кемнең эшлисе килсен ди?

Ләкин күпләр җиңел эш эзли. Эшнең җиңеле булмый инде аның. Авырлыклардан курыкмый, күңеленә яткан эш эзләргә кирәк. Уңыш кыюларны ярата.

Блиц-сораштыру

– Беренче эш итеп машина саттым. Шуның белән бергә инглиз телен камилләштердем, иң мөһиме, сату-алу эшенә өйрәндем. Икенче эшем – хәрби хезмәт. АКШ армиясендә башта рядовой булдым, соңрак, инде университетны тәмамлагач, Милли Гвардиядә офицер булып хезмәт иттем. Эмбри-Риддл Аэронавтик университетында ракеталар конструкторы һөнәренә төшендем. Piper Aircraft, Masten Space Systems һәм XCOR Aerospace компанияләрендә эшләдем, аннан соң инде, шактый тәҗрибә туплагач, Bagaveev Corporation дип аталган үз компаниямне ачып җибәрдем.

:: Бу эш Америкада инвесторларны кызыксындырамы?

– АКШта акча җәлеп итү күпкә җиңелрәк булды, монда бераз катлаулырак. Мин бит инновацияләрне, ягъни яңалыкларны тормышка ашырырга тырышам. Яңа эш ачылмаган китап шикелле, ниләр булачагын фаразлап бетереп булмый, шуңа да зур тәвәккәллек сорый, чөнки теләсә нинди этапта акчаны югалтырга мөмкинсең. Әйтергә кирәк, Америка эшмәкәрләре тәвәккәлрәк, куркып тормыйлар. Монда исә башкачарак, мәсәлән, мин Татарстан инвестицион үсеш агентлыгы белән элемтәгә кергән идем. Алар, нигездә, бина төзелеше кебек куркынычсыз өлкәләргә генә инвестиция ясарга тырышалар. Әмма биналар, складлар салып, юллар төзеп кенә алга китеп, дөньяга танылып булмый шул. Бүген термотөш реакторлар, 3-яссы басучылар (3Д-принтерлар), кабат кулланылучы орбиталь ракеталар, оптик санаклар, генетика белән шөгыльләнергә кирәк. Мәсәлән, бездә автоном электр авиация транспорты булса, башкалага Татарстанның һәр авылыннан ярты сәгатьтә килеп җитәргә мөмкин булыр иде. Мондый мөмкинлек булганда, авыллар да юкка чыкмас, киресенчә, кешеләр табигать кочагында яшәргә омтылыр иде. Менә шундый хыялларны тормышка ашыру максатыннан мин Татар конструкторлык бюросын ачарга планлаштырам да инде. Бу – бик кирәкле гамәл. Хәтерләсәгез, АКШ беренче урынга электр тогы, авиация һәм интернет инновацияләре аша иреште. Советлар Союзы исә космонавтика инновацияләре аша зур уңыш казанды.

Надир Баһавиевның шәхси архивыннан

:: Үзгәртеп кору чорында Россия космос өлкәсендә зур чигенеш ясады, дидегез. Бүгенге эшчәнлекне ничек бәялисез?

– Югары дип бәяли алмыйм. Минемчә, хәзерге идарә итүчеләр космос өлкәсенә хәрби, контроль һәм акча призмасыннан гына карый.

:: Татарстанда авиация өлкәсендә генә түгел, космос өлкәсендә дә шактый эшләр башкарыла дигән фикерләр бар. Килешәсезме?

– Килешмим. Татарстанда бәлки оптика һәм идарә өчен нинди дер компонентлар ясаладыр, әмма безгә ракетаны галәмгә җибәрү мөмкинлекләрен өйрәнергә кирәк. Мәсәлән, Кама елгасы тамагында баржалардан космодром төзергә булыр иде. Монда барып чыкмаса, Казахстан белән килешеп, анда үз космодромыбызны булдырырга, я Кырымда төзергә мөмкин. Биологик яктан ябык экосистемалар ясау эше дә көн үзәгендә тора. Төрле планеталарга очарга җыенабыз икән, димәк, әзерлек эшләрен дә алдан ук алып барырга кирәк, мәсәлән, кайчан да булса Марсны яулый алабыз икән, анда аш-суны Җирдән китермәсләр бит.

:: Гади күзлектән караганда колач җитмәслек зур эшләрне тормышка ашыру өчен ни өчен нәкъ менә Казанны сайладыгыз? Монда озакка калырга җыенасызмы?

– Соңгы араларда Казан Россиядә генә түгел, дөнья күләмендә бик җитди инженерлык үзәге булып танылды. Татар кешесе буларак, мин моңа читтән генә карап тора алмадым, җаен табып, шул дулкынга кушылып китәргә теләдем. Икенче сәбәбе дә бар. Мин Казанда туып үстем, яшьлегемне, бик сагынып яшәдем. Минем өчен башкаламның һәр почмагы кадерле. Хәзер җәяү чыгып китәм дә иске биналарга сокланып йөрим. Шәһәрнең яшеллеккә күмелүе күңелемә бигрәк тә хуш килә. Бу җәһәттән минем хыялым да бар: Казанны Бакчасарай кебек Алмасарайга әверелдерер идем. Яшел газоннарда алмагачлар утыртып, шәһәрне, чыннан да, бакча итәргә була бит. Озакка кайттыгызмы дигәннән, хәзер минем өчен бөтен Җир шары туган йортым кебек. Әлегә исәбем – Казанда рәхәтләнеп хыялларымны тормышка ашыру. Аннан кем белә, космоста яшәргә дә мөмкинлек туар. Бер караганда, кайда яшәвем артык мөһим дә түгел кебек. Ә барыбер туган җирем, мондагы дусларым, театрлары, Ак Кирмәне белән үз татарларым сагындыра.

:: Татарлар дигәннән, яңа проект буенча фәнни статьягызны һәм тәкъдимнәрегезне Татарстан Фәннәр академиясенә татар телендә юллагансыз. Яшерен-батырын түгел, технология өлкәсендә мондый адымнар безнең өчен инде гайре табигый хәл кебек тоела. Бу ни өчен кирәк? Теләктәшләр табылыр дип уйлыйсызмы?

– Мин милләттәшләремне үзе бер зур цивилизация кебек кабул итәм. Татарча уйлау башка телләрдән бөтенләй аерыла ул. Мин өч телне камил беләм. Димәк, бер үк проблема турында өч телдә дә уйлый алам дигән сүз. Шуңа күрә бу халәтне бик яхшы сиземлим. Дөрес, телләрне күбрәк белгән саен, чишелеш тә тизрәк табыла. Алар бер-берсенә ярдәм итә. Минемчә, татарлар – төрки дөньяның иң алдынгы халкы. Без моны һәрвакыт истә тотарга, бердәм, ярдәмчел булырга тиешбез. Нәкъ менә шундый хисләр мине үз халкыма хезмәт итәр өчен кайтарды да инде. Теләктәшләр дә бар. Термотөш реакторның туры тизләткечен бер инженер-энергетик белән инде планлаштыра башладык, компонентларны сатып алыргамы яки үзебезгә ясаргамы дигән сорауга җавап табу өчен татарча бәхәсләшәбез. Әлбәттә, сызымнар да татар телендә булыр дип көтелә. Ә нигә әле үз телебез шул дәрәҗәдә камил була торып, без башкаларның авызына карап торырга тиеш? Үз дөньябызны төзергә вакыт җитте дип беләм.

:: Хәзер күп ата-аналар балаларының татарча белем алуына каршы. Сәбәбе – яхшы белгеч була алмас дип куркалар. Татар мәктәбендә белем алган кеше буларак, бу хакта сезнең фикерегез?

– Үз тормышыма кагылгач, мактану булмасын, күңелдәгесен әйтәм: татар телендә укысагыз, минем кебек акыллы буларсыз. Сүз дә юк, төрле телләрне белү кешене акыллы итә. Ә үз телең ул – бөтенләй башка нәрсә. Туган тел күңелнең иң тирән почмакларына үтеп керә, бөтен барлыгыңны биләп ала, шуңа күрә иҗат иткәндә дә, эшендә дә иң якын ярдәмчең була. Минемчә, татар телен өйрәнергә теләмәү ул – татар авылыннан шәһәргә килеп русча сөйләшә алмау комплексы. Туган телеңне ташлап калдырырга түгел, киресенчә, өстәмә итеп рус телен дә, башка телләрне дә камил өйрәнү ягын карарга кирәк.

:: Татарлар арасында талантлар күп. Аларның казанышы дөньяга танылсын өчен ниләр эшләргә?

– Татар телендә инновацияләр белән шөгыльләнергә кирәк. Иманым камил, термотөш реактор турында мин татарча язган статьяга нигезләнеп термотөш реакторын төзи башласак һәм уңышка ирешсәк, бөтен дөнья татар телен өйрәнә башлар, ә Казан һәм Татарстан талантларны җәлеп итүче урынга әверелер.

:: Талантлар дигәннән, без әниегез Мәсхүдә апа Шәмсетдинованың иҗаты белән илһамланып яшибез. Музыка һәм технология... Икесе елганың ике яры кебек. Әниегезнең иҗатын сез ничек кабул итәсез?

– Без ике яр түгел, без бер үк елга. Конструкторлар эше бик иҗади бит, тик без иҗатыбызны ноталар белән түгел, металл белән язабыз. Әниемнең музыкасы мине бик илһамландыра. Хәтта беренче бизнесым да аның музыкасын кассеталарга язып сату булган иде. Гади «Багышлау» мелодиясеннән алып, Сөембикәгә ярымай кую тантанасы концерты кебек катлаулы шедеврларына кадәр яратып тыңлыйм. Әниемнең музыкасы мине сокландыра, илһамландыра, иҗат итәргә көч бирә.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ДӨНЬЯНЫ ЯРАТЫРГА БЕР КҮЗ ДӘ ҖИТӘ!

Үзеңне ничек бар, шулай яратырга кирәк! Сабада яшәүче Лилия Мөхәммәтҗанова әнә шулай ди. Кызның тумыштан бер күзе күрми. Баштарак бу кимчелегеннән читенсенсә дә, үсә төшкәч, әнисенең киңәшләре аның фикерен үзгәртә. Кешедән оялмаска өйрәнә ул.

– Без гаиләдә – ике бала. Апам сау-сәламәт. Әти-әнием мине дә туганда сау-сәламәт дип уйлый. Тик тора-бара бер күземнең кылыйлыгына игътибар итә. Шуннан соң мине табибка күрсәтергә алып баралар. Ә алар бер күземнең тумыштан күрмәвен әйтеп бирә. Әни ышанмый әле, мине Казан табибларына күрсәтергә алып чыгып китә, – дип сөйли Лилия.

Башкала табиблары шул ук сүзне әйтә. Күзне дәваларга соң була инде.

– Әни дә, бер күзе бар бит, дип әйтә дә өйгә кайтып китә. Дөрес, мәктәптә укыганда кимсетүләр, үртәүләр бар иде инде. Баштарак еласам да, аннары әнием еламаска өйрәтте. «Көчле бул!» – дип киңәш бирде. Кеше сүзенә карамаска кушты. Шуннан соң үз-үземне ярата башладым. Бер сүзгә дә исем китмәде. Киресенчә, мин кемнән ким дип яши башладым. Уйлап карасаң, дөрес тә бит. Аякларым йөри, кулларым эшли, бер күзем булса да күрә, – ди Лилия.

Кыз мәктәптә бик актив була. Ансыз бер чара да узмый. Кирәк икән, сәхнәгә менеп җырлый, бии, спорт ярышларында катнаша. Бигрәк тә стена газеталарын чыгаруны ярата. Кайчак кыздан башкалар көнләшә дә әле.

– Мәктәпне бетергәч, Казан медицина көллиятенә укырга кердем. Анда да яхшы укыдым. Соңгы курста белем алганда Сабага практика узарга кайткан идем. Җитәкчелек, укуыңны тәмамлагач безгә кайт, эш урыны бар, дип озатып калды. Шөкер, туган ягыма кире кайттым. 16 ел инде бер урында хезмәт итәм, санэпидстанциядә эшлим, – ди ул.

Лилиянең тагын бер шөгыле бар икән. Ул бәйләргә ярата. Табиблар, күзгә артык авырлык китермәскә кирәк, дисәләр дә, Лилия аларны тыңламаган.

– Моннан ун ел элек бер хезмәттәшем миңа бәйләү үрнәге тотып кергән. «Моны ничек эшлисе икән?» – ди. Тоттым да бәйләп карадым. Шул көннән бирле шәлләр бәйлим. Баштарак дус-туганнарга бүләккә генә өләшсәм, хәзер заказ бирәләр. Шәлне кияүгә чыгучы кызлар бүләккә алалар. Бер дә туктыйсым килми. Әнием телефон тотып утырсам да, компьютер ачсам да, орыша. Янәсе, күземне сакламыйм. Бер күзем булмагач, икенчесе тагын да яхшырак эшли бит, – ди ул. – Авыруым гаиләбез өчен бер сынаудыр инде. Шуңа күрә язмышка үпкәләп булмый. Яшим бит. Кәгазьдә инвалид булып саналсам да, ул сүзне бөтенләй яратмыйм. Башкортстанда яшәүче Рөстәм Нәбиевне үземә үрнәк дип кабул итәм. Ике аяксыз килеш сау-сәламәт ирләрне көнләштереп яшәп ята. Аңа сокланууым чиксез.

Ирләр дигәннән, Лилия кияүдә түгел. Дөрес, кызга күз атучылар, очрашырга тәкъдим ясаучылар күп була. Әмма ул кемнедер бәхетсез итүдән курка.

– Авыруымны белә торып, ничек инде гаилә корасың?! Шуңа да ялгыз яшәүне сайладым. Әмма соңгы араларда юлымда мине яратырлык, ничек бар, шулай кабул итәрлек кеше очрый икән, нигә әле каршы килергә дип тә уйлыйм. Язмышыма ни язылгандыр, алдагысын белеп булмый, – ди ул.

Лилия әти-әнисе белән яши. Сәяхәт итәргә ярата. Иптәш тә кирәк түгел миңа, ди ул.

– Җәй көне теплоходта сәяхәт иттем. Кешеләр белән тиз аралашам. Дус табу кыен түгел. Күптән түгел ял йортына барып кайттым. Тормышта үкенмәслек итеп яшәргә тырышам. Зарланып утырсаң, зар күп ул. Акчаның да җитәсе юк, ялның да. Әмма шөкер итә белергә кирәк, – ди Лилия. – Тормышыбыз шулкадәр рәхәт бит. Дөньяны яратыр өчен бер күз дә җитә миңа!

11 ЯШЬЛЕК МАРСЕЛЬНЕҢ ӘНИСЕ:

«Ансыз яшәүне уйлый да алмыйм»

Егыласыңны белсәң, салам түшәр идең, диләр. Бөгелмәдә яшәүче 11 яшьлек Марсель Сәләхетдиновның әнисе бу сүзләрне еш кабатлый. Моннан бер ел элек улының ишегалдында егылып, авыруга әйләнүен әле дә кабул итә алмый ул. Ул чакта баланың аягында имгәнгән, шешкән, хәтта күгәргән урын да булмый. Аягы авыртуга түзә алмаган малайны тикшерә башлагач, табиблар яман шеш барлыгын ачыклый.

– Улым өч яшеннән роликта йөри башлады. Бик актив булды, спортка тартылды. Без аны 7 яшендә дзюдога бирдек. Анда ике ел шөгыльләнде. Күп кенә җиңүләр яулады. 9 яшендә исә хоккей уйныйсы килүен әйтте. Каршы килмәдек. Үзенә ошагач, риза булдык. Улым көн саен шөгыльләнә башлады. Бар да яхшы иде бит! Кинәт кенә егылып, аяксыз калуын һич кенә дә аңлый алмыйм. Әле бит диагнозның да ниндиен куйдылар, – ди әнисе Татьяна. – Узган ел балалар өйдә укыган вакытта улым ишегалдына уйнарга чыккан иде. Ике атнадан аксаклый башлагач, табибка киттек. Алар исә аягында шеш күреп алды.

2020 елның 15 мае тормышның астын-өскә китерә. Марсельне тиз арада хастаханәгә салалар. Малайга химия терапиясе ясый башлыйлар. Май аеннан сентябрьгә кадәр химия курслары узганнан соң аларны Мәскәүгә операциягә җибәрәләр. Анда исә аякның бер өлешен кисәргә мәҗбүр булалар.

– Дәвалану ярдәм итмәде. Баламның аягын саклап каласы килсә дә, насыйп булмады. Сабыемның уң аягын кистеләр. Әмма шулай да улым күңелен төшермәде. Тереләсенә өметләнде. Өйгә кайткач, бер аягы белән яшәргә өйрәнде. Килачәккә планнар корды. Барыбер спортчы булам, дип хыялланды. Иртәрәк сөенгәнбез икән. Яман чир беркая да китмәгән булып чыкты. Улымның ике як үпкәсенә дә метастазалар киткәне ачыкланды, – ди Татьяна. – Яңадан ике курс химия терапиясе алдык. Тик аннан соң да биргән анализлар сөендермәде. Чир туктамый, яман шеш җәелүен дәвам итә. Инде нишләргә дә белмибез. Табиблар улыма ике төймә дару гына язып бирде. Хәзер шуларны эчә. Башкача ярдәм итә алмауларын яшермиләр. Аптырагач, чит ил клиникаларына язып карадым. Бер клиника улымны дәваларга риза. Әмма анда барыр өчен 14 миллион 500 мең сум акча кирәк.

Әлеге сумманы ишеткәч, Татьяна өнсез кала. Гаиләдә әле тагын Марсельдән кала ике бала бар. Ире Ленино-горскида кошчылык фабрикасында эшли, үзе «Водоканал»да контролер. Кыскасы, Сәләхетдиновларның андый акчасы юк.

– Улымны югалтасым килми. Ансыз ничек яшәрмен дигән уйны башыма да кертмим. Сабыемның терeләсенә ышанам. Бик акыллы, түзем, сабыр балам ул. Чирнең ни икәнен дә аңлый. Әмма ышана. Башкалар читтә калмас, аңа булышыр дип өметләнә, – ди ул.

МАРСЕЛЬГӘ ЯРДӘМ ИТҮ ӨЧЕН ИСӘП-ХИСАП РЕКВИЗИТЛАРЫ:

Получатель: САЛАХУТДИНОВА ТАТЬЯНА АЛЕКСАНДРОВНА
Номер счёта: 40817810262006292843
Банк получателя: ОТДЕЛЕНИЕ «БАНК ТАТАРСТАН» N8610 ПАО СБЕРБАНК
БИК: 049205603
Корр. счёт: 30101810600000000603
ИНН: 7707083893
КПП: 165502001
SWIFT-код: SABRRUMM

Игълан тактасы

КЕМГӘ КИРӘК?

• 8–10 яшьлек кыз бала өчен җәйге киемнәр бар.

Гөлназ Шамилова. Казан

***

• 4–5 яшьлек кыз бала һәм 8–9 яшьлек малай өчен киемнәр бар. Шулай ук 48–50 үлчәмдәге ирләр чалбары, күлмәкләр дә тик ята. Кирәк кешеләр булса, Казанга китереп бирәбез.

Галия. Лаеш

***

• Яхшы хәлдәге, бернична тапкыр гына киелгән 40–44 үлчәмдәге кышкы тун, 36 үлчәмдәге язгы-көзге аяк киеме бирәм.

Чулпан Вафина. Казан

***

• 46–48 үлчәмдәге хатын-кыз киемнәре бирәм. Бер дә киелмәгән кофта-чалбарлар бар. 38 үлчәмдәге аяк киемнәрен дә әзерләп куйдым.

Ләйсән Шипкова. Питрәч

***

• Яхшы хәлдәге, бернична тапкыр гына киелгән 48–50 үлчәмдәге җәйге пәлтә, 38 үлчәмдәге язгы-көзге, кышкы аяк киеме бирәм.

Наташа Садриева. Казан

***

• Яңа өйгә күчендек. Ике диван, бер караватыбызны авыр хәлдә калган гаиләгә бирер идек. Андыйлар булса, 89872076910 телефон номеры аша элемтәгә керсен иде.

Рафис Сөләйманов. Казан

КЕМДӘ БАР?

• 8–9 яшьлек кыз балага яраклы кышкы киемнәр кирәк иде.

Ләйлә Мостафина. Яшел Үзән

***

• 6–8 яшьлек ир бала, 10–12 яшьлек кыз бала өчен киемнәр кирәк иде.

Минзифа. Чистай

Ярдәм итәргә теләүчеләр булса, 89872076910 телефон номерына шалтыратыгыз.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

СӨМБЕЛ ГАФФАРОВА:

«ӘТИНЕҢ ВАФАТЫННАН СОҢ ТЕЛЕМӘ МӨНӘСӘБӘТ ҮЗГӘРДЕ»

Шәһәр мәдәнияте вәкиле. Тормышны ничек бар – шулай сурәтләүче. Шәхес баласы. Бу әңгәмәдән соң аның белән таныштырганда ихлас дип тә өстәргә кирәктер. Без аның белән Фәридә – Әхәт Гаффарларның иҗади мирасы, шәхес кадере, балалар әдәбияты турында сөйләштек.

:: Сөмбел, сез – күренекле галим һәм күренекле язучы кызы. Шәхес баласы булу иҗат өлкәсендә һәм тормышта ярдәм итәме, әллә, киресенчә, комачаулый гынамы? Кайсыдыр ишекләрне ачканда «Мин – язучы Әхәт кызы» яки «Мин – галим Фәридә кызы» дип әйткән булдымы?

– Әти-әнием исемнәрен файдаланып, берниндә ишекләрне дә аяк тибеп ачканым булмады. Ләкин, син шуның кызы бит дип, танучылар бар, әлбәттә. Ул вакытта үзеңә җылырак мөнәсәбәт тоясың. Шул ук вакытта бу «җылылык»ка иҗади уңышларыңның сәбәпче булмавын да аңлыйсың. Хәер, бу мөгамәлә миңа гына түгел, башка шәхес балаларына да кагыла торгандыр. Укыган чорда Фәһимә апа Хисамова, Флера апа Сафиуллина, Фәрит абый Яхин, Җәүдәт абый Миңнуллин, Хатыйп абый Миңнегуловның миңа мөнәсәбәтләре үзгәрәк иде. Алар бит минем әниемне дә укыткан, нинди «оя» баласы булуымны күргәннәр, белгәннәр инде. Аңа карап берсе дә билгеләрне яклап куймады. Флера апа, киресенчә, сиңа таләпләр югарырак, дип әйтә иде. Гомумән, үземә һәр җирдә таләпләрнең югарырак, катгыйрак булуын тоям. Шулай булмый ни, мин бит язучы һәм галим баласы! Ә ярдәмгә килгәндә, әти дә, әни дә нефть белән идарә итмәгән, алтын-көмешләргә уралмаган. Шуңа барысы да гади һәм кешечә булды. Әти-әнигә соңгы вакытта, сез бит Сөмбел Гаффарованың әти-әнисе, дип тә әйткәлиләр иде. Алар елмая, әтинең бигрәк тә шул сүзгә күңеле була иде иде.

Ә, юк! Искә төште. Алты яшь булгандыр миңа, хастаханәдә ятарга туры килде. Шунда безне – кызлар палатасын – малайлар төнлә теш пастасы белән буярга җыенуларын әйткән иде. Шунда минем: «Миңа теш пастасы ягылмасын! Әтием – танылган язучы!» – дип әйтүем истә. Ул сүз ярап куйды, иртән мин палатадагы пастага батмаган берденбер кыз идем.

:: Галим һәм язучы... Исән чакта тиешле игътибар күрелдеме аларга?

– Әни, галим буларак, татар халкы өчен зур эш башкарды. Ул Әхмәтһади Максуди, Садри Максуди дигән олы шәхесләрне Ватаныбызга кайтарды, аларны халыкка таныты. Бу – көне-төне архивларда казыну, безнең чыганаклар белән генә чикләнмичә, Төркиягә бару, эзләнү, туганнары белән элемтәләрне ныгыту һәм башка бик зур эшләр нәтиҗәсе. Әнине фәнни эшчәнлеге өчен бик хөрмәт иттеләр, әле дә онытмыйлар дип беләм. Әлбәттә, аның да күпме планлаштырылган эше калды... Архивларын, документларны, бертуган Максудиларның китапларын, шәхси әйберләрен, хатларын акрынлап Милли китапханәгә тапшыра барабыз. Хәзер анда Фәридә Гаффарова коллекциясе бар, берничә ел элек күргәзмәсе дә узды.

Әтигә килгәндә, мин аны тулысынча бәяләнгән язучы дип атый алмыйм. Заманында Тукай премиясенә тәкъдим ителеп, ул премиядән Гөлшат апа Зәйнашева хакына баш тарткан. Шуннан соң, соңгы ничә ел дәвамында премиягә дәгъва кылды, әмма булмады. Безнең өчен әти – Тукай премиясенә бик лаек язучы. Ул үзенең язу дәрәҗәсенең югары булуын да, язучылар арасындагы урынын да белде. Ләкин бик тыйнак булды. Аның фикеренчә, син яхшы язучы, талантлы шәхес икән, сине күрерләр һәм болай да тиешле әйберне бирерләр, янәсе, бу табигый. Чын язучы, миңа калса, шундый тыйнак була.

> Иҗат кешесенә әдәби агентлар кирәк шул. Нәкъ менә язучының мәнфәгатен кайгыртучы, аның өчен документлар җыючы, төрле бәйгеләргә, исемнәргә тәкъдим итүче. Иҗат кешеләре бу яктан бик таркау. Мөдәррис Әгъләмне генә искә төшерик. Бик зур талант, бик үзгә шәхес бит! Вакытында кадерләнсә, бюрократия эшләреннән араланса иде дә бит...

:: Соңгы вакытта татар теле турында сүз чыкса, Әхәт абыйның телен үрнәк итеп куялар. Үзенчәлекле алымы, тәгъбирләре өчен. Үрнәк икән, аның әсәрләрен ничек таратырга, ничек популярлаштырырга?

– Әтинең язу стиле чыннан да үзгә. Аны авыррак тел дип әйткәләделәр. Әсәрен уйлап укырга кирәк. Фикере, теле, стиле – барысы да баш миеңне эшләргә мәҗбүр итә, җиңел генә укырмын димә. Аның стилен мин балачактан ук тойдым. Абсурд әкиятләре канына шулхәтле сеңде ки, сүз уйнату, абсурд фикерләү минем иҗатта да бик каты чагыла, мин аннан хәтта арына да алмыйм. Әти үзгә, аны беркем белән дә бутап булмый. Әйе, йотлыгып укыла, әмма әсәрен бирелеп, кереп китеп укырга кирәк. Аның әсәрләрен ничек популярлаштырырга?.. Минемчә, яшьләр генә популярлаштыра ала. Шәхсән үзем интернет аша таратырга тырышам, әсәрләрен социаль челтәрләргә чыгарам. Әти турында, әни турында истәлекләр язам. Язучыны яшьләргә якынайту өчен бүгенге заман кораллары кирәк. Димәк, аудиоязмаларын булдырырга, интернет китап сату мәйданнарына чыгарырга, интернет аша таратырга. Башкача язучылар онытылачак. Ә бу – зур эш. Аны «Китап», «Тәртип» радиолары, Татарстан китап нәшрияты билгеле бер күләмдә башкара инде.

Язу стиле дигәннән, әтинең «Ир» дигән хикәясе искә төшә. Анда урман эчендә умарталык тотучы хатын турында сүз бара. Мин бу әсәрнең үзен дә балга охшатам. Бал кебек татлы, сузылучан, затлы әсәр ул. Шуның хәтле тәмле хикәя. Гәрчә сюжеты бик гади булса да.

:: Әхәт абый яшьләргә хәерхаһлы булды. Булдыра алганча ярдәм иткәнен дә ишетеп беләм. Синең иҗатыңа мөнәсәбәте ничек иде? «Килмешәк» драмасын, балалар өчен әсәрләреңне хуплыдымы?

– Яшьләрне бик яратты. Кулына эләккән әсәрләрне, шигырьләрне укып барды.

Аңлап бетермәсә дә, кулына яңа каләм алган кешеләрне үзеннән этеп куймады, нәрсәдер бар монда дип уйлана, кирәк булса, ярдәм итә иде. «Җирән кыз» Йолдыз Миңнуллина, Луиза Янсуарның язу стилен бик яратты. Бер фотода язучылар арасында әти тәнкыйтьче Фәрваз абый Миңнуллин (Йолдызның әтисе) белән янәшә басып тора. Узар дистә еллар, кызларыбыз да шулай иңгә-иң басып фотога төшәр, дип уйлаган микән алар?

Әти киң күңелле, гади кеше иде. Үзенә игътибар күбрәк булып китсә, уңайсызлана иде. Хәтерлим әле, Гөлчәчәк Гайфуллина тапшыру әзерләргә килгәч тә, тартынды. «Ояла-ам мин кызлардан», – дип әйтүе көлдерә иде мине.

Яшьләр дә әтине кабул итте дип әйтеп була. Әйтик, Алинә Бикмуллина Балык Бистәсендә «Әхәт Гаффар дәвамчылары» дигән бәйге оештырган иде. Мәктәп укучылары арасында хикәяләр, әкиятләр язган укучыларны әти белән бергә сайладык. Аңа бик шатланды, бик риза булды ул. Алла боерса, Алинә белән бу бәйгене дәвам итсәк иде, дип хыялланам.

Әти «Килмешәк»нең премьерасында булды. Ул аны бик яратты, караганда күзләренә яшьләр килде. «Бу – минем «Язлар моңы»на тиң әсәр», – дигән иде. Минем өчен бу – бик зур бәя.

> Әти минем язуымны гадәти нәрсә дип кабул итте. Гәрчә балачакта, язучы була күрмәгез, ул – каторга эше, дип әйтсә дә. Бәлкем, бу аның үзенчә, син шуңа әзер булырга тиеш, дип кисәтүе булгандыр. Минем әдәбиятка кереп китәчәгемне башта ук сизенгәндер. Күләмле әсәрләремне караттырмадым, тикшертмәдем аннан. Болай да «әтиең язып биргәндер» дигән шаярулар юк түгел иде.

:: Балалар әдәбияты дигәннән. Узган атнада Россия балалар китабы советының башкарма директоры Людмила Чижова белән очрашу булган иде. Ул Сергей Михалков исемендәге балалар конкурсына тәкъдим ителгән әсәрләр нигезендә балалар китабы темаларының үзгәрүе турында сөйләде. 2000 елдан башлап фантастика, балалар ялгызлыгы турында әсәрләр арткан. Безнең балалар әдәбияты ни хәлдә? Бармы хәзерге заман үсмере йотлыгып укый торган әсәрләр?

– Яшерен-батырын түгел, бүген татар балалары да русча китаплар укый. Бәлки, авылларда татарча укучы балалар бардыр, әмма күпме генә гаиләдә булсам да, татарча китап тотып утырган үсмерләрне күрмәдем. Кызым Суфияга татарча китаплар алам, бергә утырабыз, укыйбыз. Әмма йотлыгып укый, үзе сорый дип әйтә алмыйм. Хәзерге буынга фантастика ошый. Татарда андый әсәрләр азрак. Безгә яңалык соңарып килә. Авыр сорау... Балалар әдәбияты һәр заманда авыр тема булгандыр ул. Без балалардан һәр заманда артта калып барабыз. Менә минем Суфиям үсеп бара. Аңа карап, аның кызыксынуларын күз алдына алып язам икән, ул заманча яңгырар. Шушы вакытны ычкындырам икән, аннары булмый инде ул.

:: Үсмерләр «Игра в кальмара» сериалын йотлыгып карый. Мондый фильмнар турында фикерең нинди?

– Бу сериалны карамыйм. Нәрсә хакында булуын беләм, берничә роликын карадым. Үсмерләр шушындый фильмнар белән кызыксына, нишлисең. Балаң кызыксына икән, фильмны бергәләп карарга, аннары фикер алышырга кирәк дип уйлыйм. Балаңны өйрәнергә менә дигән җай бу. Бу фильмны артык кырыс, кансыз, аны караган бала тормышта да шун-

Блиц-сораштыру

– Кеше холкындагы иң күркәм сыйфат?
– Миһербанлык. Кешегә мәрхәмәт белән карамасаң, яшәү бик авыр. Явызларга да мәрхәмәт белән карарга кирәк. Икенчедән, юмор хисе. Тормышта бик ярдәм итә торган сыйфат.
– Иң начар сыйфат?
– Ерткычлык. Гәрчә яхшы, начар сыйфатлар ул – бәхәсле мәсьәлә. Гел начар гына да, яхшы гына да булып булмый.
– Хыялың?
– Алар әти белән әнигә бәйле. Әтинең музеен оештырасым килә. Әнинең Камышлы авылында Фәридә исемле чишмә ачкан идек, аны яңадан карап, төзәтеп, яңадан затлы итеп корасым килә.
– Өстәл китабың?
– Балачактан Льюис Кэрроллның «Алиса в стране чудес» китабы иде. Драматургия белән кызыксынып киткәч, аңа Сэмюэль Беккетның «В ожидании Годо»сы өстәлде. Ул – иҗатка карашны үзгәртә торган әсәр. Өченчесе – әтинең егерме биш яшендә язылган «Әҗәт» әсәре.
– Тормыш ул – ...
– ... юл. Аның нинди булуы синең үзеңнән тора. Без барыбыз да – юлчылар.

дый була, дигән фикер дә бар. Ләкин бу фильм, миңа калса, явыз дөньяда кеше булып кала белү турында. Чын дөньябызда да шушы уен бара түгелме? Тик бер ягы бар: тормышыбыздагы явызлыкка, кырыслыкка шушындый фильмнар аша күнегү бара. Менә бусы куркыныч нәрсә.

:: Сизгәнсеңдер, күбрәк Әхәт абый турында сүз куертабыз. Чөнки «ВТ»да эшләп киткән, Тукай премиясенә кандидат булуы белән дә телгә кергән, әсәрләре матбугатта чыгып торган... Ә Фәридә апа – галим, ул инде ерактарак калган кебек...
– Әни еракта калды дип әйтә алмыйм. Чөнки аны белгән замандашлары, дуслары, туганнары исән. Без исән чакта әни онытыла алмый. Хезмәтләре дә халыкка хезмәт итә. Аның бакыйлыкка күчүенә унбиш ел тулды. Бер гомер, бер карагандa. Мин дә, дөнья да, тормыш та башкача хәзер. Ләкин артка борылып карасаң, унбиш ел элекке 16 октябрь – кул сузымында гына. Ул берничек тә онытыла алмый. Әни гел янәшә, гел күз алдымда.

:: Әти-әниең алдында син эшләргә тиешле төп өч эш дип нәрсәләрне әйтер идең?
– Иманлы, шәфкатьле, кешелекле, миһербанлы балалар үстерү. Аларның дәү әни, дәү әтиләрен белеп үсүләре. Балаларым да халкыма хезмәт итсен иде. Бу – зур бурычым. Икенче эшем – әти-әнинең хезмәтләрен халыкка таныту, гел исләренә төшереп тору. Өченчесе – сайлап алган кыйбламнан тайпылмау, иҗат итү. Минем әсәрем басыла яисә сәхнәгә менә икән – ул вакытта әти-әнинең исемнәре искә алына бит.

:: Сөмбел, еш кына урысча язасың диләр сиңа...
– Урысча фикерләп язу турында әйтәсеңдер. Әйе, язу стилем шәһәрчә. Гәрчә үземә алай тоелмаса да. Кайвакыт, кыланып сөйләшәсең, дип тә әйтәләр. Шул вакытта шаккатам инде, үземә бер дә кыланмаган шикелле. Моны шәһәр баласы булуым белән аңлатып буладыр. Чөнки минем сөйләм ниндидер төбәккә бәйләнмәгән, диалекталь сүзләр азрак. Җыеп әйткәндә, шәһәрчә тел инде ул. Асфальт баласы ничек уйлый – шулай сөйләшә. Ләкин соңгы вакытта язуымда үзгәреш тоям. Язу телемә моңарчы хас булмаган сүзләр, борылмалар кереп китә. Алар шуның кадәр үзгә булып тоела, үзем дә ятсынып куям кайчак. Бу үзгәреш әтинең китүеннән соң башланды. Бәлки укыган саен телем баеый торгандыр. Шунысы хак: әти вафатыннан соң телемә мөнәсәбәтем үзгәрде, язганда телне матур күрсәтәсем килә.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ДИЛБӘР БУЛАТОВА

ТИМЕРТАУ

(ХИКӘЯ)

< Ахыры. Башы 22 октябрь санында

Мин бит беләм: җылытып, алдына куйсаң, өстенә кисеп укроп-петрушкасын сипсәң, каймагын салсаң, аны Сашенька да, оныкларым да ялт иттереп куячак. Һәр ял саен аларга барырга, тәмле ризыклар пешерергә тырыштым. Атна буе кибет ризыгы белән тукланмасын, дип, улымны җәлләдем. Ә бит оныклар да миндә үсте, беләсезме?

Наина боларны сөйләгәндә, татар бианайлары белән киленнәрен уйлыйм. Безнең бианайлар болай ук килен җанлы була алыр идеме икән, дип елмаям. Мин дә килен булган кеше. Әмма чәшке тун алып биргәннәрен, өйгә килеп, борщмы, токмачлы ашмы пешереп биргәннәрен, нишләптер, хәтерләмим.

– Әстәгый, ул киленегез нәрсә генә эшли иде соң?

– Хәзер килеп, мин дә шуны уйлыйм. Хата үземдә. Мин аларның тормышына кирәгеннән артык кысылдым бугай.

– Киленегез үзе нәрсә диде соң?

– Ул Сашаны гаепли. Телефоныннан кем беләндер язышканын тапкан. Соң, язышкан хәлдә дә, ике баланңы ятим итәрсеңме, ә? Тик төп сәбәп башкада дип уйлыйм. Иң соңыннан ул Сашага әйткән: мин өмет иткән акчаны эшли алмадың инде, дигән. Димәк, тиңсенмәгән ул... Азсынган...

Мин Наинаны ничек тә юатырга белмим...

– Бәлки, килешерләр?

– Юк. Саша аны кичерә алмаячак!

– Улыгыз әле яшь. Башканы табар, – дим.

– Мин дә шулай уйлыйм...

Сеанс вакыты чыкты. Рәхмәт әйтеп, Наинаның моңсу күзләренә карыйм. Яше алтмышларга якыная булыр. Ләкин озын буй-сыны төз. Үз көче белән дөнья көткән, таза үзәкле, алдашмый-боргаланмый яшәүче кешеләрдә генә була торганча тынычлык, зирәклек аңкый үзеннән. Хәтта кайгысын да ул ничектер артык эчкә үткәрмичә, затлы итеп күтәрә кебек. Карганмый, чыгырыннан чыкмый.

Номерга кайтуга, үтереп йокы басты. Болай тирән һәм тыныч итеп, белмим, соңгы тапкыр кайчан йоклаганмындыр...

ЛФК сеанслары моның белән генә бетмәде. Ләкин Наина башкача бу темага әйләнеп кайтмады. Барыбер дә сөйләшергә сүз күп. Мин үзем Уфа, бакчам турында сөйләдем. Аның да бакчасы бар икән. Йортын берүзе тырышып салган. Үзбәк төзүчеләренә аптыравын, аларның эшкә дә, ашка да талымсыз булуын, тамчы да аракы эчмәүләренә аптыравын әйтте. Элегрәк ел да ахирәтләре белән чит илләргә ялга йөргәннәр – шуны да белдем.

– Бәй сез болай да курортта яшисез бит инде?!

– Монда гына ятып булмый лабаса, илләр-җирләр күрәсе килә, – дип җаваплады. – Ә бит халык тик ятмый, йөреп тора. Әле ярый, коронавирус булгач, алтмыш биштән өстәге карчыкларга өйдән чыгарга ярамады, менә хәзер алар килеп тулачак. Сез уйламагыз, алар дәваланырга гына килә, дип. Иреннәренә кызыл иннек сөртәләр, матур итеп киенәләр, дискотекаларга төшәләр. Кешегә бит кеше кирәк, – дип нәтиҗә дә ясап куйды. – Менә бер елны Вьетнамга бардык. Без аннан каһвә алдык та башка нәрсәгә акча әрәм итмәдек. Ә безнең кунакханәдәге ике карчык базардан кайтып та кермәде. Әллә нәрсәләр төяделәр. «Бездә дә бар нәрсә дә бар», – дисәк, «Монда башкача», – диләр. Самолетка артык әйбер алып булмый – алар киемнәрен кат-кат киеп, багажга сыймаган тауарларын култык асларына янчык ясап элделәр.

Соңгы сеанста мин Наинага үземне берничә көн борчыган сорауны бирдем:

– Наина, сез әле яшьсез. Берәр юньле генә кеше килеп чыкса, бәлки, бәхетегезне сынап караргадыр?

– Ю-ук, сез нәрсә?! – Тавышына көлемсерәү чыкты. – Безнең нәселдә андый кеше юк. Однолюблар без.

Дөрес, уйламадым түгел бу хакта. Берәү артымнан да йөреп караган иде. Рестораннарга чакыра, бүләкләр бирә. Ник соң мине тирәли, дип уйланам. Бергә яши башлыйк, ди. Ул ашыктыра, мин ашыкмыйм. Эшкә йөрмәссең, өйдә генә торырсың рәхәтләнеп, ди. Карыйм, тора-бара ресторанда мин түли башладым. Беркөн минем туган көнгә бүләк алырга киттек. Үземә ошаган йөзекне сайладым. Кашы минем күзләремнең төсендә, шундый нәфис, матур йөзек. Ә ул акчасын өендә онытып калдырган. Син үзең түләп тор әле, соңыннан бирермен, ди.

Мине барысыннан да бигрәк шул сорау борчый иде: аның өендә көннәр буе нишләрмен? Ахырдан аңладым: егерме сутый бакчасы бар икән, шул ничә ел каралмаган, аны карарга, эшкәртергә кирәк икән. Кирәкме миңа бу? Минем үземнең дә бакчам бер дигән. Җирем алты сутый. Теләсәм, утыртам, теләмәсәм – юк. Теләсәм, чәчәк кенә чәчәм.

***

...Санаулы көн тиз үтә. Аэропортка таң сарысыннан барырга кирәк. Безне монда алып килгән таксистка – Каренга шылтыратабыз. Ул биш туларга унбиш минутта килеп тә җитә. «Сезнең аркада төн буе йоклый алмадым», – дип сукрана. Үзе, кайтканда да миңа гына шылтыратырсыз, дип ныгытып куйган иде югыйсә.

«Тойота»сы җитез, егерме чакрымдай араны бик тиз үтәбез. Шулай да Карен хакында әллә күпме белергә өлгерәбез. Ул кызы, оныклары, аларны ничек яратуы турында сөйли. Үзе утыз ел шул аэропортта йөк ташучы булып эшләгән икән. Берьюлы таксида да йөргән. Җитмеше туларга бер генә ел калса да, җиңел сөякле. Кара әле, биредә күбесе шулай төз гәүдәлеләр, дип уйлап куям. Тозлы су сөякләргә дә килешә микән? Агачлар да шуңа күптер биредә. Тау бите дип тормыйлар, өскә үрлиләр. Тик... аумасыннар гына. Бер суытып, бер җылытып, кар алкалары, бәс муенсалары артык авыр булып, ботаклары гына сынып-имгәнеп бетмәсен...

– Ә карчыгыгыз сез кайтуга чәйләрен әзерләп, көтеп торадыр инде?

Әле генә син дә мин сөйләшеп барган таксист ир бу сораудан кинәт тынып кала. Янып торган учакка кинәт су сибәләрмени.

– Җиде ел инде берүзем, – ди. – Шуңа өйдә бигрәк күңелсез. Аэропортка чыгам, пассажирлар ташыйм...

– Нишләп өйләнеп җибәрмисез соң? – дим. – Ял итүчеләр күп килә бит сезнең шәһәргә.

– Эх! – ди ул. Аның шул бер сүзенә бөтен ярдәмчесезлеге, ялгызлыгы сыйгандай. – Үзем дә уйламыйм түгел. Тик яхшы кешене каян табарга?

Шулчак минем исемә Наина килеп төшә. Алар шундый охшашлар. Җәл, телефонын алмаганмын. Аның нинди уңган, ягымлы һәм бүген нинди авыр хәлдә булуы турында Каренга сөйлим.

– Аны ничек табармын соң? – Үткер таксист гүя унбиш яшьлек кыюсыз үсмергә әйләнә. – Исеме? Исеме ничек? – Дулкынлануы тавышына чыга. Әллә Кафтау әкияте дәвам итәргә җыена инде? Карен белән Наинаның туена килеп, кымыз эчеп утырмаммы әле?

Шулчак телефон шылтырый.

– Кызым шылтырата, – ди Карен. – Настя.

Тукта, тукта, бу исемне кайда ишеттем?

– Кызыгыз Настя исемлеме? Аның ике улы бармы?

– Әйе. – Карен, аптырап, миңа борылып карый.

– Үзегез әйттегез бит бая, – дим.

– Ә-ә, хәтер начаррак шул, – ди ул, аптырабрак.

– Яңарак аерылганын да әйттегез...

– Шулай шул. Бик авыр булды ул хәл, – ди Карен, авыр сулап. – Мин алар бәхетле булыр дип шундый ышанган идем. Кызыбыз бик көтеп алынган бала булды. Бер җил-яңгыр тидерми үстердек, өйдә бер эш эшләтмәдек. Ул интекмәсен дип, ике эштә эшләдем... Тыңламады. Әнисе исән булса, юк, моңа юл куймас иде дә...

Таксист картны җөпләп куям:

– Кыенга түзеп була, рәхәткә түзеп булмый, диләр безнең халыкта.

– Ә сез теге ханымның исемен әйтмәдегез?

– Ай, онытттым, – дим, кабалана-кабалана. – Сез әйтмешли, хәтер бик начарланды әле. Аеруча ковидтан соң...

– Кем булып эшли соң? – дип өзмәде дә куймады Карен.

...Кодагыеның исемен әйтимме инде?

Ярый әле, аэропорт якын. Выжылдап килеп туктыйбыз.

– Кайсы катта эшли соң ул? – дип кычкыра Карен.

– Җиденче катта, – дим, башка килгән беренче санны әйтеп. Һәм сумкаларымны тотып, утлары җем-җем янган зур, матур һәм яңа аэропорт бинасына ашыгам. Җәмәгатем, корт чаккандай ашыгуыма аптырап, арттан иярә.

***

Самолет болытлар өстендә. Ун мең метр биеклектән Каф тавының түбәләре шундый кечкенә булып тоела. Урманының башын кар ашаган Тимертау да, беләм, тора-бара, хәтердән җуелыр. Агачларның сынган урыннары төзәлер, ауганнары урынына яңа үрентеләр калкыр. Мин монда танышкан кешеләрнең дә тау кебек хәсрәтләре уңалыр, әйе, уңалыр. Вакыт дәва бит ул. Бар да үтә, болар да үтәр...

Язучы фикере

ЮМОР ХИСЕ

Юмор хисе ул мәхәббәт кебек, я бар ул, я – юк. Булса да кыен, диләр. Кемдер, әйтик, шаярткан була – кешеләргә елмаю бүләк итәргә тели, ә аны аңламыйлар. Мыскыл итә дип уйлыйлар һәм кыйнап ташлыйлар.

Миндә юмор хисе юк. Мин – җитди кеше. Беркемгә дә елмаю бүләк итәргә теләмим. Шаяртмыйм да, шаярта да белмим. Гел дөресен әйтәм. Әйтик, мин кибеткә керәм дә:

– Зинһар өчен, колбаса бирегез әле, – дим. Сатучы елмаймый өчен «матурым» дип тә өстәмим. Намус җитми. Ну кайсы төше матур инде? Аның матурлыгын эзләп табар өчен тарихчы булырга кирәк. Ул да мине матур дими. Тик елмайган була. Һәм сорый:

– Сезгә күпме кирәк?

– Егерме биш сантиметр.

Бу юмор түгел. Минем кечкенә сумкага бары тик егерме биш сантиметр гына колбаса сыя. Тик сатучы аптырабрак кала. Баштанаяк миңа күз йөгертеп ала – безупречно. Күзгә карый:

– Ә җитдирәк булсак?

– Җитдирәк булсак та – егерме биш сантиметр.

– Гафу итегез… Тик без сантиметрлап үлчәмибез… – һәм өстәп куя. – Колбасаны.

Юмор хисе булган кеше елмаер да ары китәр иде. Мин алай итмим. Мин сумкамнан линейка алам. Нәкъ егерме биш сантиметр зурлыктагы. Сатучы миңа сәерсенеп карый да эшкә тотына. Бик җентекләп, ялгышмаска тырышып үлчи. Халыкта «Җиде кат үлчә, бер кат кис» дигән әйтем бар бит. Сатучы бу әйтемне яхшы белә бугай. Ул арада кечкенә чират хасил була. Барысы да аның линейка белән колбаса үлчәгәнен күзәтә. Бертын карап торгач, бер ханым чиратны ташлап китә. Янымда торган ир пышылдый:

– Нәрсә, монда сантиметрлап саталармыни?

– Әйе, – дим мин.

– Карале, кызык икән, – ди аның артында торган ханым. – Мин дә алыйм әле, алайса.

Ниһаять, сатучы эшен бетерә. Кисә һәм тагы бер кат үлчи. Миңа карый:

– Егерме дүрт сантиметр ярым булса ярыймы?

– Ярый. Рәхмәт.

Сатучы колбасаны үлчәмгә сала – авырлыгын да белергә кирәк бит һәм аны төреп бирә. Линейкага да суза.

– Юк, рәхмәт, үзегезгә калсын. Мин бит монда гел килеп йөрим.

Һәм читкәрәк китеп колбасаны сумкага җайлап урнаштырам. Ул арада минем артта торган баягы ирнең тавышы ишетелә:

– Миңа да шул колбасаны бирегез әле.

– Күпме бирим? – ди сатучы. Тавышында миннән котылу ләззәте сизелеп кала.

Ир беркадәр уйланып тора:

– Ну-у… Бер утыз сантиметр булса…

Хатын аңа сәерсенеп карап ала да, бәхәсләшеп тормый, мин калдырган линейкага үрелә. Шулай да бер арада минем якка ымлап ала:

– Әллә сез бергәме?

Миңа кызык. Күзәтәм. Ир дә миңа күз атып ала:

– Юк инде.

Беркадәр маташканнан соң сатучы башын күтәрә:

– Утыз биш сантиметр.

– Яхшы.

Сатучы үлчәп, төреп бирә. Ир акча түләп ары киткәч, җиңел сулап куя:

– Уф, әллә кемнәр бар бу дөньяда. – Һәм чиратта торган ханымга борыла. – Сезгә нәрсә иде?

– Икмәк, сөт.

Сатучы алып бирә. Хатын бераз уйланып тора:

– Теге колбасагызны да бирмәссез микән?

– Яхшы. Күпме үлчим?

– Миңа да шул утыз биш сантиметр тирәсе инде…

Марат КӘБИРОВ



Рәис Габдулла

22 октябрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Азнавур, быр, шаккату, Ола, Апе, зиһен, ару, Зариф, инеш, Намиб, «Омо», елт, Ивар, Тыва, «Ант», Крит, «Логан», Алов, Но, талаш.
Вертикаль буенча: Биектау, озан, Лира, илот, Шаһиморатова, ызба, Ефим, нык, Ботсвана, барка, Шон, Апанаева, тере, Лан, арту, ушат.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерә аласыз.

1 1784 елда татар морзаларына … бирелә.
А) сакал үстерү мөмкинлеге;
Б) рус дворяннары хокукы;
В) рус җирләре.

2 Казан шәһәре ничәнче елда «Россиянең спорт башкаласы» булып танылган?
А) 2009;
Б) 2013;
В) 2010.

3 «Ак барс» хоккей командасы 1995 елга кадәр нинди исем йөртә?
А) Урицкий исемендәге спорт клубы;
Б) «Итил»;
В) «Ирбис».

4 Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен бине Габдерахман ул – …
А) беренче мөфти;
Б) Сөембикә-ханбикәнең киңәшчесе;
В) Алтын Урда чоры рәссамы.

5 «Өр-яңа, бик моңлы бер җыр
Җырлыйсы килгән чагым,
Әрнеп түгел, болай гына,
Елыйсы килгән чагым».
Бу шигырь юлының авторы кем?
А) Флера Гыйззәтуллина;
Б) Илсөяр Иксанова;
В) Нәҗибә Сафина.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) Б; 4) А; 5) Б.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17243 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 358

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73,
222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+